• КЫЙССА •
МУСА ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ КЫЙССАСЫ
*5 бит*

• ЯШЬЛӘР ГАЛӘМЕ •
КАМИЛЛӘШҮГӘ ТАБА...
*10 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •
ХАРАМ, ДИМӘК ЗЫЯНЛЫ
*13 бит*

• ҖӘДВӘЛ •
ХОЗУРТВ ПРОГРАММАСЫ
*15 бит*

*№ 1 (294)* | *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* | *Җөмәдәл-әүвәл 1441*

*Гыйнвар, 2020*

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Диния нәзарәте Татарстанда Туган тел елын игълан итте



*Дәвамы 8 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Нәзарәттә балалар өчен фәнни-тикшеренү конференциясе узды



19нчы гыйнварда ТР мөселманнары Диния нәзарәте Казанның Нагорный бистәсендәге «Иман нуры» мәчете белән берлектә «Ни өчен мин үз динемне яратам?» дип исемләнгән фәнни-тикшеренү конференциясе үткәрде. Әлеге чарада катнашырга 9-14 яшьлек балалар килде. Бирелгән тема кысаларында укучылар алдан фәнни-тикшеренү эшен педагог яки ата-аналар белән бергә башкарып, үзләренең идея-дәлилләре нигезендә төзелгән проект эшләрен якладылар.

Барлык катнашучылар иртәнге тугызга нәзарәтнең конференц-залына җыелды. Балаларны, аларның әти-әниләрен Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин сәламләде:

– Әлеге бәйгедә катнашырга теләк белдерүегез – ул үзе үк сезнең җиңүегез булып тора. Һәрберегезнең темасы – олы яшьтәге кеше укырлык, әһәмият биреп өйрәнерлек темалар. Киләчәктә дә үзегезнең җитдилегегез, динебезгә мәхәббәтегез камилләшеп кенә барсын. «Ни өчен мин үз динемне яратам?» соравына һәрвакыт төгәлрәк, тирәнрәк җаваплар табып яшәргә язсын.

Алга таба әлеге мөбарәк чараны оештыру өстендә зур тырышлык куйган Казанның «Иман нуры» мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Закировка сүз бирелде:

– Әлеге чараны оештыруда, үткәрүдә зур ярдәм күрсәтүчеләргә, беренче чиратта Татарстан мөфтиятенә киң рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Мөфти урынбасары, мөхтәсибебез Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин бәйге үткәрү идеясен аңлап, әһәмиятен тоеп, аны күтәреп алды. Мин катнашучылар саны шулкадәр күп булыр дип күз алдына да китермәдем. Барыгыз да яхшылап әзерләнеп килдегез, барлык таләпләр буенча чыгышларыгызны әзерләдегез. Аллаһы Тәгалә әҗер-савaплар бирсен сезгә! Киләчәк тормышыгызда нинди генә һөнәр юлын сайласагыз да, сез бу чараларда катнашуыгызны матур хатирә, истәлек булып искә төшерерсез дип ышанам.

Көн дәвамында «Ни өчен мин үз динемне яратам?» соравына утыз биштән артык бала җавап бирергә өлгерде. Оештыручылар тарафыннан куелган төп таләп буенча, чыгыш ясау өчен биш минут вакыт бирелде. Фәнни-тикшеренү эшләренә бәя бирүчеләр хезмәтнең оригинальлегенә, актуальлегенә, яңалыгына, тикшеренүнең әһәмиятенә зур игътибар бирде. Балалар чыгыш ясаганда үзләренең ораторлык осталыкларын файдаланырга, аудиторияне үзенә каратып торырлык итеп, докладлар ясый белергә тиешләр иде. Кыска гына вакыт эчендә барлык мәгълүматны үтемле, аңлаешлы итеп җиткерү максатыннан, катнашучыларның күпчелеге презентация, күрсәтмә материаллар ярдәмендә «имтихан тотты». Моннан тыш төрле плакатлар, стена газетлары, төрле миниатюралар ярдәмендә чыгышларын баетучылар да булды.

Шулай ук, чыгышларның үтемлелеген арттыру максатыннан, балалар яттан хәдисләр һәм догалар сөйләп күрсәтте, билгеле бер эзлеклелектә тарихи вакыйгаларны тасвирлады. Гомумән, укучыларның фәнни эзләнү эшләрен зур теләк белән башкарулары әти-әниләрдә, кунакларда зур кызыксыну уятты. Конференция беренче тапкыр гына уздырылуга карамастан, катнашучылар арасында башкалабыз укучылары гына түгел, Татарстанның Сарман, Саба, Питрәч районнары, Яр Чаллы шәһәре балалары да бар иде.

Шунысы әһәмиятле: укучылар тарафыннан чыгыш өчен күп төрле темалар сайлап алынган иде: Аллаһыга мәхәббәт, күршеләрне хөрмәтләү, динебездә ятимнәргә булган мөнәсәбәт, мөселманнарның төрле бәйрәмнәргә карашы, Ислам – тынычлык дине, ислам динендә кошларны кайгырту, әйләнә-тирә мохитне саклау һ.б.

Икенде намазыннан соң, жюри җиңүчеләрне ачыклады һәм бүләкләү тантанасы уздырылды. Беренче урынны Казаннан 11 яшьлек Кәрим Фазуллин яулады. Ул «Хәзерге дөньяда һәм исламда экология» темасына чыгыш ясады. Икенче урында – «Коръән ятлау – җаңга ләззәт» темасы белән чыгыш ясаган Камилә Галиева (13 яшь, Питрәч районы), өченчедә – «Исламда кошларны кайгырту» турында сөйләгән София Ибраһимова (11 яшь, Казан). I, II, III урын алучыларга грамоталар, смартфоннар бүләк ителде.

Оештыручылар тарафыннан шулай ук һәр катнашучыга грамоталар һәм истәлек бүләкләре тапшырылды.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Татарстан имамнары һәм казыйлары өчен укулар бара



20нче гыйнварда, Лаеш районы мөхтәсибәтендә Татарстан Республикасының барлык имам-мөхтәсибләре һәм казыйлары җыелды – бирედә квалификация күтәрү курслары башланып китте. Хәзрәтләргә һөнәри әзерлекләрен нығытырга танылган дин галимнәре – гакыйдә һәм фикһ белгечләре булыша.

Имамнар өчен беренче лекцияне Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы җаваплы сәркатибе, ислам фәннәре докторы Рөстәм хәзрәт Нургалиев укый. Лекция исламда гаилә хокукы мәсьәләләренә багышлана. Катнашучыларны сәламләп, Рөстәм хәзрәт мөселман дин әһелләре өчен курсларның актуальлеген билгеләп узды – халыкның дини характердагы көнүзәк сораулары, беренче чиратта, гыйбадәт кылудан тыш, гаилә мәсьәләләре белән бәйле. Курс кысаларында исламда гаилә хокукы, аның чыганаклары һәм асылы Рәсәйнең хокукый яссылыгында карала.

«Чынбарлыкта, гаиләне һәм гаилә кыйммәтләрен саклауда ислам хокукы үз максатлары һәм бурычлары белән Рәсәй законнарының максатларына һәм бурычларына каршы килми, – дип шул ук вакытта бары ислам хокукларына кагылышлы кайбер билгеле бер нечкәлекләрне билгеләп узды Рөстәм хәзрәт. Остазның лекциясе хәнәфи мәзһәбенә караган «Әл-Һидәя», «Бәдәигъ әс-сәнаигъ фи тәртиб әш-шәраигъ», «Хашия бине Габидин» кебек китаплар нигезендә эшләнгән.

– Гаилә хокукы – мөселман хокукының иң әһәмиятле бүлекләренең берсе, ул хәләл җефетләр, балалар, шулай ук гаиләнең бүтән әгъзалары арасында шәхси һәм милек мөнәсәбәтләрен тәртипкә китерә, – дип билгеләп узды хәзрәт. – Әлеге бүлекне өйрәнүнең әһәмия-тен ачык баш миендә операция үткәрүче нейрохирург эшчәнлеге белән чагыштырып булыр иде: табиб хатасы аркасында авыру үлмәсә дә, мәңгегә инвалид булып калырга мөмкин. Монда да шулай ук: хаталы фикерләү яки әлеге бүлекне белмәү безне рухи яктан үтермәсә дә, гаилә мөнәсәбәтләре өлкәсендә иң гади нигезләрне белмәү аркасында ясала торган хата үзгәртеп булмаслык нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Квалификация күтәрү курсы кысаларында иртәгә Болгар ислам академиясе мөгаллиме, шәригать фәннәре докторы Сәйф Али Әл-Асриның «Гакыйдә» темасы буенча лекциясе көтелә.

Исегезгә төшерәбез, дәресләр татар, рус һәм гарәп телләрендә уза.

Татарстан Республикасы имам-мөхтәсибләре һәм казыйлары өчен оештырылган квалификация күтәрү курслары Диния нәзарәтенең Пленум утырышы белән тәгәлләнәчәк.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Татар теле дәресләренә нәтиҗә

14нче гыйнвар көнне нәзарәттә мәчет каршындагы ислам нигезләре курслары кысаларында алып барылган татар теле дәресләрен укытуның 2019 елгы нәтиҗәләре ясалды. Җыелыш Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, РИИ ректоры, Рәсәй ислам мәгарифе советы рәисе Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин җитәкчелегендә, укытучылар, дәреслекләр авторлары катнашында узды. Рәфикъ хәзрәт 2019 елның 15нче октябрендә яңадан республикабызның 20 мәчетендә башланып киткән татар телен өйрәнү курсларында хезмәт куючы мөгаллимнәрнең фикер-тәкъдимнәрен тыңлады, мәчетләрдә рухи тәрбия бирүдә телне өйрәтү мөһимлеге мәсьәләләренә тукталды:

– Рухи тәрбиянең иң зур бурычларының берсе – милли аңны саклап калу. Шул максаттан, елдан-ел бу сорауга еш әйләнеп кайтабыз. Рәсәй ислам институтында ун ел дәвамында «Без – татарлар» курсларын оештырып киләбез. Татарстан мөфтие тәкъдиме белән 2018 елда аны камилләштереп республикабызның ун мәчетендә өч айлык форматта укыта башлаган идек. Бүген дәресләр 20 мәчеттә 6 айлык курслар итеп оештырылды. Безгә һәрвакыт фикерләшү, методика өстендә эшләү кирәк. Шуңа 2020 елга билгеле бер чаралар планын кузаллау өчен, сезнең белән кайбер мәсьәләләрне уртага салып сөйләшергә карар кылдык.

Очрашуда катнашучылар 2020 елның ТАССР оешуга 100 ел тулу исеме астында узуын искәрттеләр һәм әлеге истәлекле вакыйга уңаеннан милләттәшләребезгә рухи тәрбия бирү эшен киң җәелдерү буенча тәкъдимнәрен ирештерделәр. Иң беренче чиратта, очрашуда катнашкан татар теле укытучылары, Татарстан мөфтияте тарафыннан мәчет каршындагы курсларда дин нигезләрен, татар теле һәм тарихын өйрәнү буенча барлык шартлар тудырылу уңаеннан рәхмәт сүзләрен җиткерделәр. РИИ мөгаллимнәре тарафыннан төзелгән «Татар теле. Башлап өйрәнүчеләр өчен» дәреслеге әлеге юнәлештә төп таяну ноктасы булуы ассызыклап үтелде. Моннан тыш, әлеге әсбап ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан уңай бәяләмә алуы искәртелде.


Мәдрәсә шәкертләренә татар телен өйрәтүдә күп еллык тәҗрибәгә ия мөгаллимә Флера Ханнанова «Татар теле» дәреслегендә дини терминология киң чагылыш табуын хуплады һәм әлеге үзенчәлек татар теле дәреслеген уникаль итүен әйтте. Моннан тыш, ул татар теле буенча эш дәфтәре әзерләп бастырырга тәкъдим итте һәм дәресләрнең сәгатьләрен арттыру буенча кайбер киңәшләрен бирде.

Рухи тәрбия бирүнең бер өлеше буларак, башкалабызның «Тынычлык», «Казан нуры», «Гаилә» мәчетләрендә татар телен өйрәтү тәҗрибәсе тыңланды. Укытучылар рухи тәрбия бирү барышында яшь контингентын һәм катнашучыларның дини инануларын күздә тотып дәреслекләрдән файдаланырга киңәш иттеләр. 2020 елда курслар оештырганда Татарстанда ислам дине һәм татар халкы тарихы мәсьәләләренә дә аерым тукталырга чакырдылар. Моннан тыш, оештыручылардан телне өйрәнүне дәвам итү төркемнәрен булдыру мөмкинлеген карауны сорадылар.

Исегезгә төшерәбез, хәзерге вакытта Татарстанның 20 мәчетендә оештырылган татар телен өйрәнү буенча бушлай курсларга 450 гә якын кеше йөри. Әлеге курслар республикабызның 15 мөхтәсибәтендә – Әгерҗе, Алексеевск, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Алабуга, Яшел Үзән, Лениногорск, Лаеш, Менделеевск, Яр Чаллы, Түбән Кама, Нурлат, Чистай, Ютазы мөхтәсибәтләрендә үткәрелә. Казанда курсларны «Ризван», «Тынычлык», «Казан нуры», «Гаилә» мәчетләрендә, шулай ук Рәсәй ислам институтында тыңларга мөмкин. Шунысын билгеләп узарга кирәк: иң күпсанлы төркем – барлыгы 60 кеше – татар телен нәкъ менә Рәсәй ислам институтында өйрәнә. Башкалабызның «Казан нуры» мәчете дә әйдәп баручылар рәтендә – 35 кеше. Татарстан шәһәрләре һәм районнары арасында Түбән Кама мөхтәсибәтендә яшәүчеләр аеруча активлык күрсәтте – биредә 30 га якын кеше татар телен өйрәнергә теләк белдерде. Лидерлар рәтендә шулай ук Яр Чаллы (23 кеше) һәм Бөгелмә (20 кеше) мөхтәсибәтләре.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары



Мөһим фикһи мәсьәләләргә карата һәрбер мөселманның үзлегеннән карар чыгарырга хакы бармы соң? Әлеге сорауга җавап бирер алдыннан гыйлемнең һәм гыйлемле кешенең Исламда тоткан урынын карап узыйк. Дин гыйлеме – Аллаһыдан бөек бүләк. Үз ихтыяры белән Раббыбыз гыйлем белән кешеләрнең аңнарын һәм йөрәкләрен бизәгән. Аллаһы шул хакта Коръәндә болай дип әйткән:

**«...Аллаһы сезнең арадан иманлы бәндәләрне һәм үзләренә гыйлем бирелгәннәрне дәрәҗәләргә күтәрә. Сезнең ниләр кылганны Аллаһы инде беләдер».**

«Мүҗәдәлә / Бәхәсләшү», 58:11

**«Кешеләргә менә шундый мисаллар аңлаттык, боларны белгәннәрдән башкалар аңлый алмас».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:43

**«Аллаһыдан коллары арасыннан бары белеме булганнар куркадыр».**

«Мәләикә / Фәрештәләр», 35:28

**«Аннан башка илаһ юк дип, Аллаһы, аннары фәрештәләр һәм гыйлем ияләре шәһадәт итте. Ул гаделлекне тота. Аннан башка илаһ юктыр, Ул – Газиздер, Хәкимдер».**

«Әл-Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:18

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бу хакта: «Аллаһы кемгә яхшылык теләсә, шуңа диндә аңлаучылык бирә. Мин бары тик таратучы гына, ә бирүче исә – Аллаһы», – дип әйткән.

Әбү Өмәмә Бәһили радыяллаһу ганһе хәбәр иткәнчә, Аллаһының Расүле галәйһиссәлам янында ике кешене искә алганнар, аларның берсе гади гыйбадәт кылучы, икенчесе галим булган. Расүлуллаһ галәйһиссәлам болай дигән: «Галим кешенең гади гыйбадәт кылучыдан өстенлеге, сезнең арадан иң соңгыгызга карата минем өстенлегем сыман. Хактыр ки, Аллаһы, Аның фәрештәләре, күкләрдә һәм җирдә булган барлык яратылганнар, хәтта үз ояларындагы кырмыскалар һәм балыклар да кешеләрне яхшылыкка өйрәтүчегә хәер-фатиха телиләр».

Башка бер хәдистә болай дип әйтелгән: «Гыйлем алу юлыннан баручыны Аллаһы җәннәткә илткән юлларның берсенә бастыра. Фәрештәләр шатлыктан аның алдында канатларын җәя. Күкләрдәге һәм җирдәге барлык яратылганнар һәм судагы балыклар галим өчен ярлыкауны тели. Хактыр ки, галимнең гыйбадәт кенә кылучыдан өстенлеге, тулган айның барлык йолдызлардан өстенлеге сыман. Хактыр ки, галимнәр – пәйгамбәрләрнең варислары. Һәм хактыр, пәйгамбәрләр мирас итеп динарлар яки дирхәмнәр калдырмаган, аларның мирасы – гыйлем. Кем аны алган икән, шуңа галәмәт зур өлеш тигән».

Шунлыктан галимнәрнең бердәм фикеренә күрә, фикһи мәсьәләләр буенча бары тик мөҗтәһид галим генә мөстәкыйль карар чыгара ала. Ә мөҗтәһид дәрәҗәсенә ирешергә теләүче исә түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1. Фикһның төп мәсьәләләре буенча җәмәгатьнең бердәм килешенгән фикерләрен (иҗмагъ) һәм аларның мәзһәбләргә караган вариантларын белергә.
2. Фикһ методларын куллана белергә.
3. Гарәп телен мөкәммәл белергә.
4. Коръәнне һәм аның тәфсирен яттан белергә.
5. Тулы ачыкламаларын да кертеп, өч меңнән дә ким булмаган хәдис белергә.
6. Тормышында дин һәм әдәп кагыйдәләрен төгәл үтәргә, тәкъва булырга.

Иң югары дәрәҗәдәге соңгы сөнни мөҗтәһидләр булып мәзһәбләргә нигез салучылар санала.

Мөҗтәһидләр Коръәнне һәм хәдисләрне дөрес итеп аңласыннар өчен Аллаһы Тәгалә аларга хикмәт һәм зирәк акыл, ихтыяр көче һәм тагын бик күп өстенлекләр биргән, бу өстенлекләрнең иң беренчесе – ихлас тәкъвалык, ә аннан соң – йөрәкләренең илаһи илһам белән нурлануы. Әлеге искиткеч затлар турында кыскача мәгълүмат бирик.

Беренче мәзһәбнең нигез салучысы – Әбү Хәнифә бине Ногман бине Сабит –Имам Әл-Әгъзам. Аның яшәгән еллары: 699-767. Яшьлегендә ул бик яхшы гомуми һәм дини белем алган, бик тә тәкъва, юмарт, аз сөйләшүчән, һәрвакыт уйланучан кеше булган. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең кайбер сәхабәләре белән очрашу бәхетенә ирешкән. Бөек имам төннәрен намазда үткәргән. Һәр төндә бер намазда ул Коръәнне тулысынча укып чыга торган булган. 40 ел дәвамында ул иртәнге намазны төнге намаз тәһарәте белән башкарган. Хәнәфи мәзһәбе Һиндстанда, Пакыстанда, Бангладешта, Көньяк Африка Республикасында, Иорданиядә, Ливиядә, Суданда, Ливанда, Кытайның бер өлешендә, Төркиядә, Рәсәйдә, Урта Азиядә, Мисырда, Әфганстанда һәм башка илләрдә (мөселман дөньясының өчтән берендә) таралган.

Икенче мәзһәбкә нигез салучы – Мәлик бине Әнәс Әл-Әсбәһи. Аның яшәгән еллары: 713-795. Яшь вакытында йөзгә якын галимнән дәрес алган. Күп китаплар язган һәм шулар арасында «Әл-Мүвәттә» – иң элекке хәдис җыентыкларының берсе. Ул хәдисләрне бик яраткан һәм аларны бервакытта да тәһарәтсез укымаган. Имам гел дөресен генә сөйләгән, берәр нәрсәне белмәгәндә, беркайчан да «белмим» дип әйтүдән тартынмаган. Аннан белем алучылар арасында хәтта патшалар булса да, ул бөтен шәкертләрен тигез күргән. Мәлики мәзһәбе Әлҗәзаирда, Туниста, Мароккода, Суданда, Мисырның бер өлешендә һәм Африканың башка җирләрендә таралган.

Өченче мәзһәбнең нигез салучысы – Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд бине Идрис Әш-Шәфигый, Мәлик бине Әнәснең укучысы. Аның яшәгән еллары: 767-820. Ул яхшы белем алган. Аны тыйнаклыгы, гаделлеге, киң күңеллеге һәм намуслыгы өчен хөрмәт иткәннәр. Аның хәтере бик яхшы булган – 9 яшендә ул инде Коръәнне яттан белгән. Имам беренче булып фикһ нигезләрен туплап «Ысул әл-фикһ» китабын язган. Рамазанда ул намазларында тулы Коръәнне 60 тапкыр укып чыга торган булган. Төннәрен 3 өлешкә бүлгән: өчтән берен намазда үткәргән, өчтән берен – белем алуда, ә калган өчтән берен йокы өчен калдырган. Бу мәзһәб хәнәфи һәм мәлики мәзһәбләре йогынтысында формалашкан һәм аларның үзенчәлекләрен үз эченә алган. Шәфигый мәзһәбе Индонезиядә, Малайзиядә, Таиландта, Һиндстанның бер өлешендә һәм Шри-Ланкада, Гарәбстанда, Фәләстыйнда, Угандада, Кениядә, Мисырның бер өлешендә, Сүриядә, Көньяк Африка Республикасында һәм башка илләрдә таралган.

Дүртенче мәзһәбкә Әбү Габдуллаһ Әхмәд бине Хәнбәл нигез салган. Аның яшәү еллары: 780-855. Ул күп кенә танылган галимнәрдән белем алган һәм Пәйгамбәр галәйһиссәламнең күп санлы хәдисләрен туплаган. Аның «Мөснәд» исемле җыентыгында 40 меңнән артык хәдис бар. Ул имам Шәфигыйның иң яхшы укучысы булган һәм остазы аның турында: «Мин Багдадны калдырып киттем, һәм анда Әхмәд бине Хәнбәлдән дә галимрәк, тыйнаграк, намуслырак һәм заялырак кеше юк иде», – дигән. Имам Әхмәд һәр көн сәен 300 рәкәгать нәфел намазлар кылган. Аның җеназасында 800 меңнән артык ир кеше һәм 60 мең хатын-кыз катнашкан. Хәнбәли мәзһәбе Согуд Гарәбстанында таралган.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең «Кешеләрне (дингә) өйрәтегез, җиңеләйтегез һәм катлауландырмагыз», – дигән сүзләренә таянып, әлеге бөек галимнәр һәр мөселманның шәригать кушканнар буенча яшәүләрен җиңеләйткәннәр. Аларның хезмәте динебезгә керткән шундый зур өлеш булып тора ки, әгәр дә Аллаһының ярдәме булмаса, моны башкарып чыгу мөмкин булмас иде, чөнки бу бер генә кешенең дә көче җитәрлек эш түгел. Шунлыктан, Коръәнне һәм сөннәтне тирәнтен өйрәнеп, башкаларга өйрәтү эшенә гомерләрен багышлаган кешеләргә карата ихластан рәхмәтле булу – һәрбер чын мөселманның бурычы. Мөхәммәд Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм шуны әйткән: «Өлкәннәребезне хөрмәт итмәгән, кечеләребезгә мәрхәмәтле булмаган һәм галимнәребезне ихтирам итмәгән кеше минем өммәтемнән түгел».

**«Ислам дине нигезләре» китабыннан**

# Муса галәйһиссәлам кыйссасы

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

## Муса галәйһиссәлам Фиргавен сараенда

Муса галәйһиссәламнең әнисе бер балта остасына агачтан тартма эшләргә куша. Тартманың эченә ул мамык түши, ә тышына, су үткәрмәсен өчен, сумала сылый. Улын тиешенчә туендыры да, Аллаһы Тәгаләгә тапшырып, баланы шул тартмага куеп, тартманы суга сала.

Аллаһы Тәгалә әмере белән, елга агымы тартманы Фиргавен сараена кадәр алып килә дә, ярга чыгарып ташлый. Фиргавен хатынының хезмәтчеләре су алырга дип килгәч, тартманы табалар һәм аны алып кайтып, Фиргавен хатынына бирәләр. Фиргавен хатыны тартманы ачып карагач, анда нур сирпеп торучы баланы күрә. Шунда аның күңелендә бу балага карата сөю уяна. Баланы күрүче башка кешеләр дә үзләрендә шундый ук хис тоялар. Хәтта Фиргавен үзе дә соңыннан бу балага нык ияләшеп, аны ярата башлый. Аллаһы Тәгалә Коръәндә бу хакта болай дип әйткән:

**«Мин сиңа Үземнән бер сөю бирдем. (Кешеләрнең күңелләренә сиңа карата сөю орлыклары чәчкәнгә күрә, сине күргән берсе синнән башка тора алмас хәлгә киләчәк). Син – Минем күзәтүем астында үстерелүең өчен».**

«Та Һа», 20:39

Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә Фиргавен сараеның бар кешеләре күңелләренә Муса галәйһиссәламгә карата сөю орлыгы сала. Әмма бераз вакыт үткәч, сарай кешеләре күңелләрендә: «Бу бала кем, ул каян килгән? Бәлки ул Фиргавен хакимлегенә чик куяр өчен туган баладыр?» – дигән шик туа. Алар бу бала бәрәр исраилле баласыдыр дип шикләнәләр. Фиргавеннең якыннары киңәшкә җыелалар һәм бу баланы үтерергә карар итәләр. Әмма Фиргавеннең хатыны Асия бинте Мөзәһим аларга каршы чыга һәм ирен балага тимәскә күндерә. Асия бинте Мөзәһим моның белән генә чикләнеп калмый, ул бар көче белән Муса галәйһиссәламне яклый, Фиргавен бу баланы яратсын өчен бар көчен сала.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Фиргавеннең хатыны: «Менә минем дә, синең дә күз нурыбыз. Аны үтермәгез! Бәлки, ул безгә файда китерер яки без аны уллыкка алырбыз», – диде. Әмма алар белмиләр иде».**

«Касас / Хикәя», 28:9

Әнә шулай, Асия бинте Мөзәһим тырышлыгы белән Фиргавен һәм аның якыннары Муса галәйһиссәламне үтерү уеннан кире кайталар. Бу бала аларның эзләгән дошманы булуы хакында хәтта башларына да килми.

Риваятьләрнең берсендә: «Асия Фиргавенгә: «Менә минем өчен дә, синең өчен дә күз нурыбыз», – дип әйтте. Ә ул: «Синең өчен – шулай, ә миңа аның кирәге юк», – дип җавап бирде, дип әйтелә.

Соңыннан бу шулай булып чыга да. Аллаһы Тәгалә Фиргавен хатынын хак юлга күндерә, ә Фиргавеннең үзен Муса галәйһиссәлам кулы белән юк итә.

Асия бинте Мөзәһим, Муса галәйһиссәлам таягын бик зур еланга әйләндереп, могҗиза күрсәткәч, иманга килә. Фиргавен, хатынының иманга килүен күреп, аны каты җәзаларга тарта.

Әбү Һөрайра тапшырган риваятьтә болай дип әйтелә: Фиргавен Асияне дүрт кадак белән җиргә кадаклап, аның өстенә авыр таш куярга дип әмер бирә. Шулвакытта Асия Аллаһыдан болай дип сорый: «Раббым, Миңа җәннәттән, Үз яныңнан йорт-урын бир, мине Фиргавеннән һәм аның (начар) эшләреннән коткар. Мине бу динсез халыктан арала!»

Асия бинте Мөзәһим Аллаһы Тәгаләгә үзе өчен җәннәтел-мәвадан йорт-урын сорап ялвара. Җәзалау-газаплауларның барысын да сабырлык белән үтеп, ул үзе теләгән иң югары дәрәҗәдәге мәңгелек ялга лаек була.

Кайбер кыйссаларда фиргавен Асияне, кире үз диненә кайтарыр өчен, төрле газапларга дучар итә, дип тапшырыла. Тик шул вакыт эчке сиземләү аша аңа җәннәттәге урыны күрсәтелә. Һәм ул бернинди дә авырту сизмичә җан бирә. Аның тәненә куелган таш инде җансыз гәүдәгә салына. Асия бинте Мөзәһим иманда ныклык өлгесе булып тора, ул аны мәңгелек тәмуг утына дучар итәргә тырышкан Фиргавенгә каршы чыга һәм аның иң изге хатын-кызы булып Җәннәтнең иң югары дәрәҗәсенә ирешә.


Хәдистә Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Җәннәтнең иң изге хатын-кызлары – Хәдичә, Фатыйма, Мәрьям һәм Асия бинт Мөзәһим», – дигән сүзләре тапшырыла.

## Бала яңадан әнисенә кайта

Муса галәйһиссәламнең әнисенең хәле һәм аннан соң аның белән ниләр булганы турында Раббыбыз Коръәндә бу рәвешле бәян итә:

**«Мусаның әнисенең күңеле бушап калды. Ул (улын алып киткән сандыкның дулкыннар арасына кереп киткәнен күргәч, кычкырып,) аны ачар дәрәҗәгә җитте. Әгәр дә Без ышанганнардан булуы өчен күңелен куәтләндермәгән булса идек. Аның (Мәрьям исемле) апасы: «Артыннан бар!» – диде. Һәм ул аны ерактан күзәтте. Әмма алар (Фиргавеннең кешеләре аның баланы күзәткәнен) белмәделәр».**

«Касас / Хикәя», 28:10-11



Муса галәйһиссәламнең әнисе, баласын үлемнән коткарып калу өчен, аны сандыкка салып, Нил суы буйлап агызып җибәргән. Аның бар уйлары улы турында булган. Иртән, сандыкның Фиргавен сараена эләгүен ишеткәч, ул чак акылдан язмаган. Фиргавен хәзер минем баламны үтерә инде дип, кычкырып-кычкырып елый башлаган. Шул вакытта аңа Аллаһыдан ярдәм килгән. Аллаһы Тәгалә илһам булып аңа элек вәгъдә иткәнен исенә төшергән. Шуннан соң Муса галәйһиссәламнең әнисе ныклап бу вәгъдәгә ышанып, аның нәтиҗәләрен көтә башлаган. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә аңа түземлек һәм сабырлык ирештермәгән булса, ул кайгы-сагышыннан үзенең кем икәнлеген хәтереннән югалткан да булыр иде. Муса галәйһиссәламне дә үз улы дип әйтер иде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

**«Әгәр дә Без (сүзебезгә) ышанганнардан булуы өчен (сабырлык һәм ныклык биреп һәм янә тынычлык иңдереп,) күңелен куәтләндермәгән булсак, (һичшиксез, ул «аһ, улым!» дип кычкырып, үзен фаш итәчәк иде».**

«Касас / Хикәя», 28:10

Аллаһы Тәгалә аның күңеленә улы кире кайтачак дигән ышаныч сала. Шунда йөрәге тынгы таба, улы белән ни булганын белер өчен ул кызын Фиргавен сараена җибәрә. Кызы шунда хезмәт иткәч, аңа тиешле хәбәрне җиткереп торган. Ул үзен сидерми, читтән генә Муса галәйһиссәлам артыннан күзәтеп йөри башлый, аның турында тиешле мәгълүмат җыя. Ул Фиргавеннең Муса галәйһиссәламне үтермәвен, аны уллыкка алуын белә. Моннан тыш, ул сарайда булган бар вакыйгалар турында да белеп бара һәм кайтып әнисенә сөйли.

Фиргавен һәм аның хатыны Муса галәйһиссәламне бик яраткач, алар аны үз уллары кебек үстерергә карар итәләр. Муса галәйһиссәламне туендыру өчен Фиргавен хатыны, бала имезүче хатыннарны сарайга чакыртып ала. Ул алар арасыннан иң яхшысын сайлап алырга уйлый. Ләкин Муса галәйһиссәлам аларның берсен дә кабул итми. Шуннан соң Фиргавен хатыны Муса галәйһиссәлам ачтан үләр дип бик курка. Бу вакыйга турындагы хәбәр тиз арада бар тирә-якка тарала. Мисырның бар җирләренә дә, яшь баланы имезүче хатын кирәк, дип игълан итүче сөрәнчеләр җибәрелә.

Аллаһы Тәгалә бу турыда Коръәндә болай ди:

**«Без (апасының күзәтүеннән) алдан (бер могҗиза буларак) имезүче (сөт аналарыннан имүне) аңа тыйдык. Ул (апасы сарайга керелгән бер генә хатыннан имүне кабул итмәгән бала аркасында бик нык борчылган Фиргавеннең гаиләсенә): «Сезнең өчен аны (имезеп үстерүне) өсләренә алган һәм аңа игелек теләгән бер йорт халкын сезгә күрсәтимме?» – диде».**

«Касас / Хикәя», 28:12

Муса галәйһиссәламнең апасы Фиргавен сараенда бала имезүче хатын эзләүләрен һәм таба алмауларын белгәч, сарайга килеп: «Мин сезгә бер өйнең җәмәгатен күрсәтимме, ул хатын сезнең өчен баланы имезеп тәрбияләр һәм ул җәмәгать балага яхшы нәсыйхәт бирүчеләрдән булыр», – диде.

*Дәвамы киләсе санда.*

■ **Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Республикасы мөфтие**

# Аллаһы Тәгаләнең ихлас колларымы без?

*«Күрсәм ышанырмын», ди кеше,*
*«Ышансаң күрерсең», ди Аллаһы.*

Галәмнәрне юктан бар кылган, безне – Адәм балаларын дөньяга китереп, Үзенең чиксез нигъмәтләрен яудырып торучы Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз булса иде.

Галәмнәргә рәхмәт булып җибәрелмеш сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватшәрифәләребез барып ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә безнең кылган хәерле гамәлләребезне кабул итеп, ике җомга арасында кылынган гөнаһларыбызны гафу әйләсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә Үзенә иман китергән бәндәләрне «колым» дип атый:

**«Аллаһы Үзе теләгән колларына нигъмәтләрен тәгаенли...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:90

**«Ул коллары белән идарә итә, һәрнәрсәгә Хуҗа вә Җиңүчедер».**

«Әнгәм / Терлек», 6:18

**«Ул – коллары өстендә чиксез куәтле. (Гамәлләрегезне язып) Саклаучыларны (фәрештәләрне) дә сезгә Ул юллый».**

«Әнгәм / Терлек», 6:61

Мәктәпләрдә өйрәнгәнчә, кол – хуҗасы кушканнарны берсүзсез, карусыз үтәүче, безнең очракта мөселман – буйсынучы. Ләә иләәһә илләллаһ, Мухәммәдүр расүлуллаһ, дип ихластан бер тапкыр гына әйтсә дә, кеше мөселман була һәм Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, фарызларны үтәп, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте буенча эш итәргә тиешбез. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйткән:

**«Мин кешеләрне дә, җеннәрне дә Үземә гыйбадәт кылсыннар өчен яраттым».**

«Зарият / Таратучы», 51:56

Гыйбадәт – Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен эшләнгән ачык яки яшерен гамәлләр, Аллаһы риза булган сүзләр. Гыйбадәтләр тел, тән һәм мал белән башкарыла.

Тел белән башкарыла торган гыйбадәт: Аллаһыны һәрдаим искә алу – «бисмилләһ», «сөбхәналлаһ», «әлхәмдүлилләһ», «Ләә иләәһә илләллаһ», «Аллаһу әкбәр» һәм башка зикерләр әйтү.

2. Тән белән гыйбадәт кылу: намаз уку, ураза тоту һ.б.

3. Мал белән гыйбадәт кылу: үзеңнең малыңнан мескеннәргә, мохтаҗларга өлеш чыгару:

а) зәкят бирү: елга бер тапкыр нисаб күләмендә (230 мең) ел дәвамында хәрәкәтсез яткан (банкта яки башка саклау урынында) байлыгы булса, 2,5% ын бирү. Нисаб күләмендә байлыгы булмаганнар зәкяттән азат ителә.

б) гошер бирү: бакчабызда су сипмичә үстергән уңышның (Аллаһы биргән) уннан берен, су сибеп үстергәннең (Аллаһы әмереннән) егермедән берен мохтаҗларга, мескеннәргә, дин юлында йөрүчеләргә, шәкертләргә бирү.

в) Корбан бәйрәмендә көндәлек хаҗәтләрдән тыш сарык сатып алырлык акчасы булганнарга Аллаһы ризалыгы өчен корбан чалу вәҗиб гамәл.

г) нәфел садакалар: үз теләгең белән, теләгән вакытта һәм теләгән күләмдә бирелә торган садакалар.

Садака – ислам шәригате буенча үзеңнән артканны түгел, үзеңә дә кирәкле малдан мескеннәргә, мохтаҗларга, дин юлында йөрүчеләргә дә өлеш чыгару.

Мөселман булу Аллаһы Тәгаләнең колы булу, гыйбадәт кылу гына түгел, ул кешенең яшәү рәвеше, мөселман әхлагын, әдәбен саклау, гөнаһлы гамәлләрдән – зина кылу, гайбәт сөйләү, ялганлау, сүгенү, харамнан тыелу; игелекле гамәлләр кылу – дуслык, туганлык, кардәшлекне саклау һәм үстерү, үзара яхшы мөгамәлә, өлкәннәрне (яше һәм дәрәҗәсе буенча) хөрмәт итү, мескеннәргә ярдәм итү, яшь буынга Ислам нигезләрен өйрәтү.

Үзебезнең бүгенге һәм үткәндәге гамәлләребезгә күз салыйк әле. Аллаһы Тәгалә кушканнарның кайсысын Аның колы буларак үтибез? Ә үтәү өчен нәрсә кирәк? Җавап гади: иманлы булу кирәк. Иман – ул Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә, фәрештәләренә, пәйгамбәрләренә, Аллаһының китапларына, Кыямәт көненә, тәкъдиргә – тормышыбызда булган яхшы һәм начар хәлләрнең Аллаһы Тәгаләдән булуына берninди дәлилләрсез, шартларсыз, үзең күргәндәй ышану.

Аллаһы Тәгалә безгә төрле нигъмәтләр һәм алар белән файдаланыр өчен әманәт итеп тән һәм төрле әгъзалар биргән. Иң әһәмиятлесе: фикерләү сәләте, акыл нигъмәте һәм аның аркылы мөселманга иң зур байлык – иман байлыгы биргән. Коръәндә бик күп аятьләр «Әй иман китергән бәндәләр....», дип башлана һәм без – иманлы кешеләр, мөселман буларак, Аллаһы Тәгаләнең коллары буларак, динебезнең биш терәге булган: иман китерү, биш вакыт намаз уку, Рамазан аенда бер ай ураза тоту, зәкят бирү, матди мөмкинлеге һәм сәламәт булганнарга хаҗ кылу гамәлләрен үтибезме?

Кыямәт көнендә беренче сорау намаз турында булачак. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Алар (акыл ияләре) аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә Аллаһыны зикер итәләр һәм күкләр белән җирнең яратылышы турында фикерлиләр...»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:191

Бу әмерләрне башкарып, Аллаһыга тәкъвалыгын күрсәтер өчен кешегә нәрсә кирәк? Зиннәтле бинамы? Юк! Шактый юл узарга мәҗбүр итә торган махсус билгеләнгән урынмы? Юк! Зур байлыкмы? Юк! Тәүбәгә килеп, ничек телим, шулай яшим дигән нәфес, теләкне җиңеп, ялкаулыкны ташлап, Коръәннән «Фәтихә һәм тагын берничә кыска сүрә һәм аять өйрәнергә, намаз укыйм дип ниятләргә, тәһарәт алырга, теләсә кайсы чиста, башкалар комачауламый торган урынга, кыйблага карап басып, намазны үтәргә кирәк, чөнки бөтен җир йөзе – мөселман кешесе өчен намаз урыны. Кызганыч, үзебезне Аллаһы Тәгаләнең коллары икәнлегебезне истән чыгарып, бу дөньяга Аллаһы безне сынау өчен генә ятратканны да онытып, нәфес колы булып яшәвебезне дәвам итәбез. Балаларыбызны да җитеш, зиннәтле тормышта яшәргә өйрәтәбез һәм кайчак моның өчен үкенергә дә туры килә.

Кешедән «ник намазга басмыйсың» дип сорагач, ул «әле вакыт җитмәгән», «вакыт юк», «намазга гөнаһларын юу өчен зур гөнаһлылар гына баса», дигән җаваплар ишетәсең. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Һәрбер кеше хаталы һәм иң хәерле, мактаулы хаталанучылар – хаталарын танып, аны төзәтергә теләүчеләр», – диде.

Коръәндә болай дип әйтелгән:

**«Тик (көферлектән) тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына (бу аларга кагылмас)! Аларның (тәүбәләре сәбәпле сөртелгән) начарлыкларын Аллаһы күркәм нәрсәләр белән алмаштырачак. Аллаһы Гафу итүче, Рәхимле».**

«Фуркан / Аеручы», 25:70

Димәк, тәүбәгә килгән һәркем Аллаһының ярлыкавына лаек. «Җирдә бик зур гөнаһлылар да яши, шуларны Аллаһы Тәгалә җәзалаганын күрсәм, намазга басам», – дип әйтүчеләр бар. «Кылган гөнаһларына күрә Аллаһы инсаннарны җәзалый барса, Җир йөзендә бер генә җан иясе дә калмас иде. Ләкин Аллаһы җәза бирүне Үзенә генә мәгълүм бер билгеләнгән вакытка кичектереп килә. Вакыты җиткәч барысы да үз өлешен алыр.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

**«Хакыйкатьтә, Аллаһы Үз колларын күреп тора»**, – дип әйткән.

«Мәләикә / Фәрештәләр», 35:45

Аллаһы Тәгаләнең яраткан колы булу, Аның ризалыгына ирешү өчен, Аның кушканнарын үтәү, тыйганнарыннан тыелу өчен теләк, тырышлык, авырлыкларга һәм артык рәхәткә сабыр булу кирәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

**«Бу (газап) – Аллаһы бер кавемгә биргән нигъмәтне үзгәртмәгәне өчен, алар күңелләрендә булганны (яхшы холыкны начар омтылышка) үзгәртмәсәләр. Һичшиксез, Аллаһы – Ишетүче һәм Белүче»,**

«Әнфәл / Табыш», 8:53

**«Дога кылучының догасын Миңа ялварган чагында ук кабул итәм. Миннән кабул итүне сорасыннар һәм Миңа иман китерсеннәр. Бәлки, алар (дини һәм дөньяви мәнфәгатьләренә ирешеп,) туры юлдан барырлар»**, – дип әйткән.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:186

Кызганыч, без гаепне үзебездән түгел, башкалардан эзлибез. Биш вакыт намазның һәрберсенә ун-унбиш минут вакытны кызганабыз, ә Аллаһы Тәгалә биргән иң кыйммәтле вакытны сәгатьләр буе телевизор каршында утыруга, урамда гайбәт сөйләүгә әрәм итүебезне башыбызга да кертмибез. Ирләргә: Аллаһы Тәгалә биргән бер атнадагы 168 сәгатьнең бер сәгатен иң бөек намаз – җәмәгать белән укыла торган җомга намазына биреп, олы бурычыбызның берсен генә булса да үти башлыйк.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр! Акылыбызны эшкә җигеп, иманыбызны ныгытып, мәңгелек тормыш – җәннәт һәм җәһәннәм турында уйланып, бу дөньядагы соңгы сулышыбызны алганчы Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, Аның яраткан коллары булып, дөньялыкта Аллаһының ризалыгына, Ахирәттә рәхмәтенә ирешергә омтылып яшәргә Аллаһы Тәгалә насыйп итсен.

■ **Сираҗиев Габдулла Әхмәдулла улы,**
**Питрәч районы,**
**Күн мәхәлләсе, «Иман нуры» мәчете**

# «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмасында ни өчен «истава» сүзе «овладел» дип тәрҗемә ителгән?



**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм. «Калям Шариф. Перевод смыслов» басмасында сез «истава» турында аятьне «овладел Аршем (и всей остальной вселенной)» дип тәрҗемә иткәнсез. Ни өчен әлеге тәрҗемә сайлап алынды? Бу аятьнең мәгънәсен бозмыймы?

**Җавап:** Вәгаләйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Тәрҗемәне әзерләгәндә без ислам фәннәре буенча киң күләмле классик хезмәтләргә таяндык. Болар – тәфсирләр генә түгел, гакыйдә һәм башка фәннәр буенча да китаплар. Барлык бәхәсле сораулар, шул исәптән «мүтәшәбихат» (Аллаһыга карата сүзгә-сүз мәгънәне куллану рөхсәт ителмәгән текстлар) аятьләрен тәрҗемә итү мәсьәләсе дә коллектив рәвештә хәл ителде.

«Истава» фигыле гарәп телендә берничә мәгънәгә ия: өлгерү, олы яшькә керү, тигезләшү, ия булу, мөрәҗәгать итү, күтәрелү, үсеп җиту, ныгу (тамыр җәю), урнашу, утыру (утырып тору) һәм башкалар.

Имам Мәлик болай дигән: «Күтәрелү билгеле, әмма (әлеге күтәрелүнең) образын күз алдына китерү мөмкин түгел, әмма моңа ышану мәҗбүри, ә (образ турында) сорау – яңалык» («Сияр» әз-Зәһаби, 7/415).

Бездән Аллаһыны тасвирлау белән бәйле ике этапны узу таләп ителә, аның сүзгә-сүз мәгънәсе тән сыйфатларына күрсәтә. Беренче этап – әлеге тасвирламаны, инкяр итмичә һәм кире какмыйча, ачышның бер өлеше буларак кабул итү. Икенче этап – кимчелекләргә күрсәтә торган әлеге сүзләрнең мондый мәгънәләрен кире кагу: тән сыйфатлары, чикләүләр һәм физик образ.

Бу урында, аңлатмаларга күчмичә (тәэвил), тукталырга мөмкин (һәм кирәк тә).

Әмма кайбер галимнәр тәэвил кылуга – гарәп телендә сүзләрне куллануга һәм Аллаһы Тәгаләгә карата кимчелеккә күрсәтми торган мәгънәгә туры килгән аңлатманы сайлауга каршы килмиләр.

Коръәнгә аңлатма бирүче, әүвәлге чор галимнәрдән булган имам Ибне Җәрир Әт-Табари (һиҗри буенча 310 нчы елда вафат була) «Әл-Бәкара» (Сыер) сүрәсенең 29 нчы аятенә аңлатмада болай дип яза:

«Иң якын мәгънәләрнең берсе – алар өстеннән (күкләрдән) күтәрелгән».

Алга таба:

«Аллаһы хакимлеккә һәм идарәгә ия булуы белән күтәрелгән, биредә күтәрелү мәгънәсе күчүне, бер урыннан юкка чыгуны аңлатмый».

Имам Әбү Бәкер Әл-Бәйһакый (һиҗри буенча 458 нче елда вафат була) «Әл-Әсма вә әс-сыйфат» китабында болай дип яза:

«Миңа остаз Әбү Мансур бине Әбү Әйүб (һиҗри буенча 421 нче елда вафат), Аллаһы аннан разый булсын, соңгы дәвер галимнәрнең «истава» ул – ия булу һәм өстенлек итү» фикеренә килүләре хакында язган иде».

Башка сүзләр белән әйткәндә, «истава» сүзен рус теленә «возвысился» (дәрәҗәгә һәм хакимияткә карата, әмма урында булуга һәм аннан күчеп йөрүгә карата түгел) һәм «овладел» дип тәрҗемә итү рөхсәт ителә, чөнки мондый аңлатмалар Коръән һәм Сөннәт белгечләреннән, абруйлы имамнардан килә.

Эш барышында безнең тарафтан алып барылган мүтәшәбихат тәрҗемәсе принциплары турында «Калям Шариф. Перевод смыслов»та кереш сүздән укырга мөмкин (IX – XII битләр).

## Намазда бишенче рәкәгатькә бассаң, нишләргә?

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм!

Ачыклык кертергә ярдәм итсәгез иде. Кичә мин өйлә намазын укыганда, дүртенче рәкәгатьтән соң, онытылып китеп, өченче рәкәгать дип уйлап, киләсе рәкәгатькә басканмын. Аннары гына моның бишенче рәкәгать икәне башыма килде. Аннары, мин намаздан чыгып, аны кабаттан укыдым, чөнки нишләргә кирәк икәнлеген белмәдем.

**Җавап:** Вәгаләйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Имам Кудури рахмәтуллаһи галәйһи «Мохтәсар Әл-Кудури» хезмәтендә болай дип яза:

«Соңгы утыруда ялгышкан (ягъни гомумән соңгы утыруны башкармаган) кеше, (ялгышлык белән) бишенче рәкәгатькә басып, әгәр ул бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен үтәргә өлгермәгән булса, утыруга кире кайтырга тиеш; аннары ялгышлыктан соң үтәлә торган сәҗдәи сәһү кыла, бишенче рәкәгать укылмый. Әгәр ул бишенче рәкәгатьтә сәҗдә кылып өлгергән булса (ягъни исенә төшергәнче бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен үтәргә өлгерсә), аның фарыз намазы юкка чыга һәм ул нәфел намазына әверелә һәм аңа алтынчы рәкәгатьне өстәргә кирәк. Әгәр намаз укучы кеше дүртенче рәкәгатьтән соң «Әттәхият» дәвамлылыгында утырса, һәм шуннан соң, бу беренче утырудыр дип, сәлам бирмичә торса, ул бишенче рәкәгатьнең сәҗдәсен башкарганчы кәгъдәгә кайта (аннары сәҗдәи сәһү башкара). Әгәр ул бишенче рәкәгатьне сәҗдә белән башкарырга өлгергән булса, аңа тагын бер рәкәгать һәм сәҗдәи сәһү өсти, аның фарыз намазы дөрес була, ә ахыргы ике рәкәгате аның өчен нәфел намазы була».

Сезнең очракта исә, искә төшерүгә үк, кабаттан утырырга һәм, сәҗдәи сәһү кылып, намазны тәгәлләргә кирәк иде.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

## Балдан зәкят түләнәме?

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм! Әйтегез әле, балдан зәкят түләнәме?

**Җавап:** Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Имам Кудури (рахмәтуллаһи галәйһи) үзенең «Мохтәсар Әл-Кудури» хезмәтендә болай дип яза:

«Әгәр дә бал җыелган уңышыннан гошер түләнә торган җирдән алынган булса, бал күп яки аз булуга карамастан, аның уннан бер өлешен бирергә кирәк».

Югарыда әйтелгәннәрдән тагын шуны аңларга кирәк, уңыштан һәм җиләк-җимештән зәкят (гошер) түләр өчен, нисаб (зәкят чыгару өчен тиешле булган иң аз күләм) юк.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

## Банкта бурычларны түләтү бүлегендә эшләргә ярыймы?

**Сорау:** Әссәләмү галәйкүм!

Аңлатма биреп үтә алмассызмы, мөслимәгә банкта эшләргә ярыймы һәм анда бурычларны түләтү белән шөгыльләнергә, дөресрәге, хезмәткәрләрне моңа өйрәтергә мөмкинме? Рәхмәт.

**Җавап:** Вәгаләйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Мөселманның бурычлы кеше белән үз-үзен тоту кагыйдәләре «Әл-Бәкара» (Сыер) сүрәсенең 280 нче аятендә болай дип әйтелгән:

**«Әгәр (бурычлы) авыр хәлдә булса, аның хәле җиңеләйгәнче көтү (кирәк). (Тарлыкта яшәгән кешеләрдән алачагыгызның бөтенен яки бер өлешен) гафу итсәгез, сезнең өчен яхшырак. Әгәр сез (бурычны кичерүнең сезгә нинди зур савап китерәчәген) белсәгез иде!»**

Әлеге аятьтән аңлашылганча, кичектерү – бурычлы белән үзара хезмәттәшлекнең иң кулай ысулы. Шуңа күрә бурычны түләтү процессы мәҗбүри характерда була алмый. Моннан тыш, банклардагы барлык бурыч йөкләмәләре – риба нигезендә төзелгән килешүләр, ә бу исә Коръәндә тыелган. Мондый төр бурычларны түләтүдә теләсә нинди төр ярдәм – үзенә күрә золым (рәхимсезлек һәм гаделсезлек). Шуңа күрә, акча эшләүнең мондый төре бик шикле.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

**dumrt.ru сайтыннан**

# Диния нәзарәте Татарстанда




22 нче гыйнварда ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумының күчмә утырышы уздырылды. Пленум барышында имам-мөхтәсибләр һәм казыйлар бертавыштан 2020 елны Туган тел елы дип игълан итәргә карар чыгарды. Шулай итеп, мөфтият үзенең быелгы бөтен эшчәнлеген мәчетләрдә татар телле мохит булдыру, татар телен өйрәтү, татар рухи мирасын популярлаштыру, халыкта милли үзаңны тәрбияләү, милли үзенчәлекләрне саклап калу кебек максатларны исәпкә алып башкарачак. Хәер, Диния нәзарәте күпсанлы татар телле проектлар һәм башлангычларны тормышка ашыру тәҗрибәсенә ия, алар исәбендә: Әлмәттә «Нур» татар мәктәбе, Балтачта малайлар өчен эшләп килә торган «Ярдәм» мөселман пансионаты, Алабугада «Ихсан» мәктәбе, мәчет каршындагы татар теле курслары, ММЧ, китаплар һ.б. Моннан тыш, Диния нәзарәте һәм мәчетләрнең эшчәнлеге, эшлекле мөнәсәбәтләре, халык белән эшләү юнәлеше дә татар телендә алып барыла.

Пленумның көн тәртибендәге төп мәсьәлә булып ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм аның оешмаларының 2019 елда башкарган эшчәнлегенә нәтиҗә ясау, шулай ук 2020 елга максатлар билгеләү иде. Бу темага баш доклад белән Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин чыгыш ясады. Ул иң элек мөфтиятнең үткән җиде елда ирешелгән уңышларга нәтиҗәләр чыгарды һәм яңа унъеллыкны ачып җибәрә торган 2020 елга куелган максат-бурычларны барларга чакырды.

Беренче чиратта, Рөстәм хәзрәт Татарстан мөфтияте һәм нәзарәт кул астында хезмәт куючы дин әһелләре тарафыннан соңгы елларда илдә һәм республикада Ислам үсешенең нигезен тәшкил иткән күп кенә фундаменталь проектларны гамәлгә ашыруга тукталып үтте: Коръән бастыруның татарча традицияләрен торгызу, Рәсәйнең дини әдәбият базарын «тазарту» максатыннан «Хозур» нәшрияты тарафыннан татар дини мирасы турында китаплар бастыру, яшьләр арасында дәгъват эшчәнлеге алып бару, мәчетләрдә татар телен өйрәтүне уңышлы рәвештә оештырып җибәрү. Соңгысы хакында аерым тукталып, ул мәчеттә башланып киткән татар теле курсларының, елдан-ел камилләшеп, хәзерге вакытта егерме мәчеткә кадәр җиткерелүен әйтеп китәргә мөмкин.

Диния нәзарәтенең иң зур казанышы итеп Коръәнне бастыруның татарча традицияләрен торгызуда күрәм, – дип белдерде хәзрәт. – Хәтерләсәгез, бу максаттан 2013 елда мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы белән мөфтияттә Коръәнне өйрәнү бүлеге булдырылды. 2016 елда әлеге бүлек белгечләре тарафыннан Коръәннең классик булып танылган «Кәлам Шәриф» басмасы нәшер ителде. 2017 елда басма Рәсәйдә беренче мәртәбә халыкара стандартларга яраклык турындагы Шәһадәтнамәгә ия булды. Нәтиҗәдә, без бастырган Коръән китабы мөселман дөньясында зур кызыксыну уята. Заманында бөтен дөньяга таралган мәшһүр «Казан басма»сы кебек! 2018 елда Изге Коръәннең Дубай халыкара премиясе үзәге Кәлам Шәрифне әзерләп бастыру өчен «Казан басмасы»ның 1803, 1914 һәм 2016 елларда чыккан китапларын куллана башлый. Халыкара дәрәҗәдә танылу БДБ илләренең дини оешмаларының да игътибарын җәлеп итте: нәзарәт басмасының электрон файллары Аллаһы ризалыгы өчен Үзбәкстан мөфтияте һәм Белоруссия мөселманнары Диния нәзарәтенә тапшырылды. Әнә шулай итеп, Казанда татарлар тарафыннан әзерләнгән Коръән басмасы Рәсәйне һәм Рәсәй мөселманнарын Ислам дөньясында иң алдынгы өммәтләрнең берсе буларак тәкъдим итте.

Рөстәм хәзрәт шулай ук былтыр нәшер ителгән «Калям Шариф. Переводы смыслов» һәм «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» басмаларына да тукталды: «Коръән – Исламның нигезе. Коръәне булмаган, аны белмәгән халык дини яктан надан була. Хәзер инде татарлар чын мәгънәсендә китаплы халык булды, хак Исламның алдагы үсеше өчен фундаменты бар, дигән сүз. Шуның белән бергә Диния нәзарәте Коръәнне җәмгыятьтә дөрес аңлату өчен дә тулы бер база булдырды. Басмалар Татарстан Президенты, «Рәсәй – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнехановның илкүләм премиясенә лаек булды. Килешәсездер: Коръән мәгънәләренең рус һәм татар теленә тәрҗемәсен бастыру – бөтен Рәсәй мөселман өммәте тормышында һәм аерым алганда татар дөньясында әһәмиятле вакыйга булып тора. Бу ике фундаменталь хезмәт мөфтият тарихында Коръән мәгънәләренең үзе әзерләгән беренче тәрҗемәсе, ул Татарстанда игълан ителгән Тәфсир елы кысаларында дөнья күрде. Аларны халык көтеп алды, чөнки безгә хәзерге заман татар һәм рус телләрендә әзерләнгән, ышанычлы һәм мәгънә ягыннан ялгышлыклары булмаган тәфсир кирәк иде. Мөфтиятебез Казаннан торып Рәсәйдә Исламның алдагы үсешенә дөрес бастырылган Коръән һәм аның чын мәгънәләрен аңлатып тулы бер нигез булдырды. Хактыр ки, татарлар – иң алдынгы мөселман халыкларының берсе! Татар мөселманнарын шушы олы дәрәҗәгә ирештергән өчен Камил хәзрәткә олы рәхмәт, билгеле!

Аерым игътибарны Рөстәм хәзрәт «Хозур» нәшрияты эшчәнлегенә дә юнәлтте. 7 ел эчендә нәшрият 250 исемдәге хезмәт бастырды, аларның гомуми тиражы 500 мең данәне тәшкил итте. Узган елны «Хозур» яңа рекордка иреште һәм 89 исемдә китап нәшер итте. Моннан тыш, мөфтият тарафыннан дәгъват эше массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан да алып барыла. Бүгенге көндә мөфтият тарафыннан федераль масштабтагы мөселман медиакиңлеге булдырылды – «Хозур ТВ» телеканалы, «Азан» интернет-радиосы, «Дин вә мәгыйшәт» газетасы, «Шура» альманахы гамәлгә куелды, «Умма» газетасы чыгып килә, «Ислам тудей» порталы эшли. «Хозур ТВ» мөселман телеканалы Татарстан, Башкортстан, Түбән Новгород, Оренбург, Мәскәү, Воронеж өлкәләрендә күрсәтә, «Шура» журналы да Рәсәйнең берничә төбәгенә җибәрелә, «Ислам тудей» БДБ киңлегендә иң популяр ислам порталы булып санала.

Ә Darul-kutub.com электрон китапханәсе өчен былтыр Казанда 1913 елга кадәр дөнья күргән 166 китап сканер аша узды, – дип белдерде Рөстәм хәзрәт. Әлеге проект Диния нәзарәте тарафыннан 2013 елда гамәлгә ашырыла башлады. Шул рәвешле, хәзерге вакытта Darul-Kutub.com электрон китапханәсе 1000 гә якын иске китапны (бу 1200 гә якын том), шул исәптән татар дин галимнәренең революциягә кадәр дөнья күргән классик хезмәтләрен үз эченә сыйдыра. Борынгы китапларны электрон версиягә күчереп, Диния нәзарәте бәяләп бетергесез эш башкара: киләчәк буыннарга үзебезнең мирасны җыеп тапшыра һәм теләгән һәркем өчен аның белән танышырга мөмкинлекләр тудыра. Бу фәнни институтлар дәрәҗәсендәге хезмәт!

Әмма дәгъват өлкәсендә нәзарәтнең иң мөһим казанышы итеп Рөстәм хәзрәт имам-хатыйблар тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмәне кабул итүне атады: «Нигезләмә имамнар һәм гомумән дин кардәшләребез арасындагы ислам гыйбадәтләренә кагылышлы барлык бәхәсләргә зур нокта куйды». Исламның асыл кыйммәтләрен халык арасында аңлату һәм таратуның тагын бер уңышлы алымы – «Даруль ифта» мөселман call-үзәген булдыру:

Рәсәйдә ул федераль номерлы шәригать мәсьәләләре буенча бушлай консультация бирә торган беренче мөселман Call-үзәге булып тора, – диде хәзрәт. – Сигез ай эчендә нәзарәтнең шәригать белгечләре call-үзәк аша Рәсәйнең төрле почмакларыннан – Татарстан, Башкортстан республикаларыннан, Түбән Новгород, Оренбург өлкәләреннән, Мәскәүдән һ.б. төбәкләрдән килеп ирешкән 5000 гә якын мөрәҗәгатьне кабул итте. Ягъни белгечләр көненә якынча 30 мөрәҗәгатьне карый дигән сүз.

Шулай ук соңгы 7 ел эчендә мөфтиятнең яшьләр сәясәте дә тулы көчкә гамәлгә ашырыла башлады. Былтыр мөселман яшьләре өчен мөфтият тарафыннан 19 проект тормышка ашырылды. Болар – мөселман яшьләре форумнары, иҗади бәйгеләр, яшьләрнең хәйрия чаралары, спорт ярышлары һ.б. яңа буын мөселман кешеләрен бер хәрәкәткә берләштерә, аларга сәләтләрен үстерергә, үз юлларын табарга ярдәм

# Туган тел елын игълан итте

итә.

Нәзарәтнең хәйрия эшчәнлеген дә Рөстәм хәзрәт югары бәяләде. 2016 елдан башлап нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды үзенең эшчәнлеген көчәйтеп, мохтаҗларга ярдәм күрсәтү юнәлешләрен киңәйтә, хәйриячелекнең яңа алымнарын үзләштерә. Шушы еллар эчендә битараф булмаган кешеләр ярдәмендә 200 дән артык авыру баланың дәвалану курсларын түләү өчен акча җыела. 2019 елда гына «Зәкят» хәйрия фонды тырышлыгы белән 53 авыру баланың дәвалану курсына акча җыелды.

Әмма «Зәкят» фонды хәйрия чараларын тормышка ашыру өчен акчаны җәлеп итүнең башка юлларын да тапты, – диде мөфти урынбасары. – 2017 елдан башлап Фонд һәртөрле дәүләт һәм коммерцияле грантлар конкурсларында уңышлы катнашып килә. Моның уңай нәтиҗәсе дә күзгә күренерлек булды: Казанда бүгенге көндә инвалид балалар һәм аларның ата-аналары өчен «Хәят» социальләшү үзәге эшләп килә. Татарстанда мондый ярдәм үзәге әлегә бердәндер! Быелтыр исә аның кысаларында авыру балаларны шәфкать туташы һәм социаль нянялар карамагына вакытлыча калдырып тору мөмкинлеге дә ачылды.

Мохтаҗлар арасында азык-төлекләтә ярдәмгә дә олы ихтыяҗ сизелүе әйтелде. Шуңа күрә 2019 елда гына да Рамазанда 900 мохтаҗ гаиләгә азык-төлек тапшырылды, Корбан гаетендә 1150 гаиләгә 5,5 тонна ит бирелде, көзен 1110 тонна гошер садакасы таратылды.

Шунысы да әһәмиятле: узып киткән унъеллык Татарстанда 168 мәчет ачылуы белән тәмамланды. Былтыр гына 18 яңа мәчет сафка басты, өстәп тагын Чистайда «Камалия» үзәге, Норлатта Әхмәдзәки хәзрәт Сәфиуллин исемендәге мәгариф үзәге, Яшел Үзәндә мәдрәсә бинасы ачылды. Бүгенге көнгә тагын 54 мәчет төзелеп бара. Бу уңайдан Пленумда яңа мәчетләргә татар дин әһелләре исемнәре бирергә 2020 елның юбилей даталарга бай булуын исәптә тотарга тәкъдим ителде. 2020 нче елда:

– Габделхак хәзрәт Саматов тууына 90 ел тула;

– Габделхәбир хәзрәт Яруллин тууына 115 яшь тула;

– Габделхак хәзрәт Садыков тууына 125 яшь тула;

– Әбү Мансур Әл-Матуридиның тууына 1150 ел тула;

–Мөхәммәдсадыйк Иманколыйның тууына 150 ел тула;

– Печән базары мәчете 175 еллыгын билгели;

– Әҗем мәчете салынуга 130 ел тула.

Пленум утырышында катнашучылар алдында 2019 елда башкарган эшләре хакында шулай ук Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, РИИ ректоры Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин, нәзарәтнең Голәмәләр шурасы сәркатибе Рөстәм хәзрәт Нургалиев, мөфтинең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча киңәшчесе Равил хәзрәт Зөфәров, нәзарәтнең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат Әюпов, «Хозур» нәшрият йорты, «Зәкят» хәйрия фонды, «Вакыф» фонды җитәкчеләре хисап тотты, эш юнәлешләре буенча нәтиҗәләр чыгарды.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Мөхтәрәм кунак – доктор Фарук Хамад килүе

**Мөфтият эшчәнлеге белән Гарәп Әмирлекләреннән доктор Фарук Хамад танышып китте**

23 нче гыйнварда Татарстан мөфтияте резиденциясенә Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән мөхтәрәм кунак – Мөхәммәд V исемендәге университет ректоры, профессор Фарук Мәхмүд Хамад һәм аның ярдәмчесе Рашед Әл-Менхали килде. Танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесен Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин каршы алды.

Очрашуда шулай ук нәзарәтнең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ректорынының уку-укыту буенча урынбасары Зөлфәт хәзрәт Габдуллин катнашты.

Доктор Фарук Хамад, беренче чиратта, бик теләп һәм зур кызыксыну белән Татарстанга сәфәр кылуы хакында җиткерде, аерым алганда, кайбер хис-кичерешләре белән дә уртаклашты:

– Бүген Рәсәй ислам институтында булдым, уку йортының эшчәнлеге белән таныштым. Шәкертләрне тәрбияләүгә зур игътибар бирелә, биредә радикализм һәм экстремизмның барлык принциплары кире кагыла, ягъни, бездәге кебек урта ислам юлыннан баралар. Укучылар ватанпәрвәрлек сыйфатларын үзләштерәләр – ә бу исә яшь буын өчен бик мөһим. Алар Татарстанны үстерү өчен күп тырышлык куялар.

Республикабыз хакында җылы, ихлас сүзләр җиткерүе өчен Рөстәм хәзрәт мөхтәрәм кунакка рәхмәт сүзләре җиткерде һәм мөфтият эшчәнлеге белән якыннан таныштырып үтте: Татарстан мәчетләренең эшчәнлеге, төп үзенчәлекләре хакында мәгълүмат бирде, ислам яңарышы тарихы турында сөйләде. Мөфтинең беренче урынбасары шулай ук татар дин әһелләренең дөньякүләм ислам гыйлеме үсешенә керткән өлешләренә дә тукталды, хәзерге вакытта имам-хатыйблар әзерләү, аларның белемнәрен күтәрү өлкәсендә зур эш башкарылуын билгеләп үтте. Моннан тыш, күпләгән борынгы китапларны халкыбызга кайтару, аларны саклау һәм аны киләчәк буыннарга җиткерү хакында хәбәр бирде.

Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин доктор Фарук Хамадка «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан татар милләтенең күренекле дин әһеле, галим Шиһабетдин Мәрҗани




хезмәтләренең җыелмасын бүләк итте. Галимнең алты томлык җыентыгы үз эченә танылган «Хакк әл-мөбин фи мәхәсин әудагъ әд-дин», «Хизәмәт әл-хәваши лиидәхәт әл-гәваши», «Мөстәфәд әл-әхбәр фи әхвәл Казан вә Болгар», «Нәзурәтел-хак фи фәридатил-гыйшәэи вә ин ләм йагыйбиш-шәфәкъ», «Китаб әл-хикмәт әл-бәлига әл-җәниййа фи шәрех әлгакаид әл-хәнәфиййә. Китаб әл-фәваид әл-мөхиммә» китапларын туплаган. Хезмәтләрен автор иске татар һәм гарәп телләрендә язган.

Доктор Фарук Хамад 1966 елдан уку-укыту һәм фән өлкәсендә эшли башлавы хакында әйтте. Ә иң кызыгы: чыганакларны өйрәнү барышында аның беренче булып танышкан китаплары – Казан дин галимнәренең ислам буенча язган хезмәтләре булган. Ул зур кызыксыну белән укый-укый Мәрҗани китапларын кабул итеп алды һәм бик теләп танышачагы турында җиткерде.

Очрашудан соң мөхтәрәм кунакка нәзарәт буенча экскурсия оештырылды, ул шулай ук «Дарул-ифта» call-үзәге эшчәнлеген үз күзләре белән күреп китте. Кунак икенде намазыннан соң «Ярдәм» мәчетендә, ә 24е Болгар ислам академиясендә, шимбә көнне КФУда булды.

■ **dumrt.ru сайтыннан**

# Камилләшүгә таба...

***2019 елда мөфтият тарафыннан яшьләр өчен 19 проект тормышка ашырылган***

2019 елны мөфтият яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендәге эшчәнлеген менә шушы саннар белән тәмамлады.

Иң мөһим эшләр – мөселман яшьләренең Кышкы һәм Җәйге форумы, **«Ислам. Беренче адымнар»**, **«Мөселман яшьләренең фикер алышу клубы»**, **«Мөслимәләр мәктәбе»**, **«Чиста мәчет»** проектлары **«Яшь вәгазьче»** дини татар бәйгесе, **«Ак кәгазьгә – яңа юл»** хәйрия акциясе, , Шиһабетдин Мәрҗани кубогына джиу-джитсу буенча Бөтенрәсәй турниры, ТР МДНе кубогына милли көрәш һәм армрестлинг буенча Бөтенрәсәй турниры, шулай ук ТР мөфтиенең актив мөселман яшьләре һәм волонтерлары белән очрашуы, мөфти тарафыннан махсус стипен-дияләр һ.б.

Моннан тыш, 2019 елда кайбер проектларга яңа сулыш өрелде һәм шул рәвешле социаль проектлар үзгәреш кичерде: **«Лекторий»**, мөслимәләр өчен **«Яшь килен»**, **«IMAN»** ирләр клубы, мөслимәләр өчен **«Коръән укырга өйрәнәбез»** проектлары эшләп китте.

ТР МДНенең яшьләр сәясәтендәге аеруча да мөһим юнәлешләренең берсе – мөселман волонтерларының хәрәкәте. Бүгенге көндә ТР МДНе волонтерларының базасына 1000 нән артык кеше теркәлгән. Биредә 14 тән 80 яшькә кадәр булган кешеләр исәпләнә. Алар һәр елны традицион Республика Ифтарларын оештыру, Болгар җыены, «Рамазан – изге гамәлләр ае» акциясендә һәм гошер садакасын җыеп-таратуда актив катнаша.


Диния нәзарәтендәге иң эффектив яшьләр мәйданчыгы булып мөфтият тарафыннан елына ике тапкыр үткәрелә торган мөселман яшьләре форумын әйтеп узу мөһим. Мәгълүмати-белем бирү һәм дискуссион проект яшь кешеләргә аралашу, белемнәр белән уртаклашу һәм үзләренең идеяләрен тормышка ашыру мөмкинлеге бирә. Форум традицион рәвештә февраль һәм июль айларында Болгарда уза. Быел мөселман яшьләренең Кышкы форумында 40 ир-егет һәм 18 яшьтән 35 яшькә хәтле булган мөслимә, ә Җәйге форумда барлыгы 200ләп кеше катнашты. Катнашучылар Рәсәй төбәкләреннән һәм чит илләрдән килүчеләр иде.

Елсаенузаторган республикакүләм дини **«Яшь вәгазче»** бәйгесе талантлы, куйган максатларына ирешә белгән, гыйлемгә омтылышлары булган егетләрне ачыкларга һәм алга таба аларның сәләтләрен халкыбызга әдәп-әхлак өйрәтүдә кулланырга ярдәм итә. Бәйгенең региональ этаплары ТРның 48 мөхтәсибендә үтте. Быел республикакүләм дәрәҗәсендә бәйге ике тапкыр оештырылды. Гомумән алганда, бәйгедә имам, хәзрәт һәм укытучы вазифаларында хезмәт итмәгән 15 яшьтән 35 яшькә хәтле булган 30 ир-егет катнашты. Бәйге яшь буын вәкилләренә рухи, әхлакый-этник тәрбия бирү, тамашачылар алдында чыгыш ясаганда сөйләм күнекмәләрен камилләштерү, яшьләр мохитендә иҗади көчне ачу максатларында үткәрелә.

**«Мөселман яшьләренең фикер алышу клубы»** һәм **«Мөслимәләр мәктәбе»** исемле яшьләр проекты 2016 елдан бирле үз эшчәнлеген алып бара. 2019 елда алар яңалык кичерде һәм шул рәвешле **«Лекторий»** һәм **«Яшь килен»** проектлары барлыкка килде. «Лекторий» проекты эшләп киткән вакыттан башлап, танылган шәхесләр катнашында биш иң популяр темага – мәзһәбләр, секталар, дөньяви фәннәр, Дарвин теориясе, хәләллеккә кагылган лекцияләр һәм фикер алышуга багышланган кичәләр үтте. Биредә офлайн-күзәтүчеләрдән тыш, һәр-даим онлайн режимда якынча 350 онлайн тамашачы катнашты.

**«Мөслимәләр мәктәбе»**ндәге үзгәрешләр шулай ук берәүне дә битараф калдырмады. **«Яшь килен»** курсларының беренче агымы 50 дән артык гүзәл затларны җыйды. ТР МДНе тарафыннан оештырылган әлеге проект мөселман яшьләре арасында гаилә кыйммәтләрен ныгыту максатын күз уңында тотып эшли, ул шәригать һәм татар халкы гореф-гадәтләре ягыннан никах мәсьәләләсендәге төрле сорауларга багышланган. Катнашучыларга 7 офлайн-очрашу һәм 6 онлайн-видеодәрес форматында борынгыдан килгән бәби чәе, бишек җыры, кыз озату һәм башка күңелле милли гореф-гадәтләребез, никахның дини һәм хокукый яклары, ир белән хатынның хокуклары һәм вазифалары, мәһер, никах килешүе, хатын-кыз һәм ир-ат психологиясе һәм башкалар турында сөйләнде. Моннан тыш, мөслимәләр өчен милли ризыкларыбызны әзерләү, балалар карау, тәрбияләү, кунаклар кабул итү һәм башка осталыклар серенә ирешү мөмкинлеге дә булды.

Яңа пректларны барлаганда **«IMAN»** ирләр клубына тукталып үтү мөһим. Ул күпсанлы мөселман аудиториясе соравы белән оештырылган. Проектта 18 яшьтән олырак булган, Ислам кысаларында рухи яктан һәм шәхес буларак үсәргә, камилләшергә әзер булган ир-егетләр катнашты.




Алар өчен атна саен очрашулар, җитди практикалар, спорт белән бәйле булган һәм башка төр шөгыльләр уздырылды. Хөрмәтле остазлар, хәзрәтләр проектта катнашучыларга көндәлек тормышның һәр сферасына үтеп кергән шәригать нормалары, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең Сөннәтен үз тормышында куллану һәм хак мөселманның нинди әхлакый сыйфатларын үстерүнең кирәклеге, рухи авырулардан котылуның ысуллары турында сөйләделәр. Шулай ук үз һөнәрләренең белгечләре кешенең физиологиясе, максатчанлыгы өлкәсендәге темаларга чыгышлар ясадылар.

Проектлар арасында мөслимәләр өчен оештырылган **«Коръән укырга өйрәнәбез»** дип аталган экспресс-курсларның ихтыяҗы зур булып чыкты. Дәресләргә 25 мөслимә йөрде. Алар өчен гарәп алфавитын, авыр хәрефләрнең мәхрәҗен (гарәп авазларын дөрес итеп яңгырату), тәҗвид кагыйдәләрен (Коръән уку кагыйдәләрен), «Идгам», «Мәд» төркеме, калын һәм йомшак хәрефләр, тукталу билгеләре кагыйдәләрен өйрәтү өчен 6 дәрес уздырылды.

Актив һәм сәламәт яшәү рәвешенә чакыру – яшьләр сәясәтенең аерылгысыз өлеше булып тора. Спорт чаралары яшь мөселманнар һәм шулай ук традицион конфессия вәкилләре арасында берләштерү, дуслыкны ныгыту, үзара аңлашу чарасы булып хезмәт итә. Алар гомум кабул ителгән кыйммәтләр системасын һәм башка диннәрне дә аңлау максатын күздә тотып, шәхесләрдә актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлтелгән. Шиһабетдин Мәрҗани кубогына джиу-джитсу буенча һәм ТР МДНе кубогына милли көрәш һәм армрестлинг буенча Бөтенрәсәй турнирлы спорт чаралары мөселман яшьләре арасында зур популярлыкны яулады. Актив мөселман яшьләре Татарстанда игълан ителгән **«Экстремизмга – Юк!»** айлыгы кысаларындагы программаны тормышка ашыруда да катнашты. Шулай итеп Казанда мөселман һәм православ яшьләре арасындагы катнаш төркемнәрдә волейбол буенча дустанә ярышлар узды.

Макулатура җыю буенча оештырылган **«Ак кәгазьгә – яңа юл»** дип аталган республикакүләм акциясе Казанда гына түгел, республикабызның башка районнарында да киң таралыш алды. Акция нәтиҗәләреннән билгеле булганча, 10 тонна кәгазь җыелган. Җыелган акчалар «Зәкят» Хәйрия Фондының авыру балаларына материаль ярдәм буларак тапшырылган.

Моннан тыш, дини уку йортларында гыйлем алучыларны яхшы итеп гыйлем алуга кызыксындыру, талантлы яшьләрне табу һәм аларны киләчәктә үз һөнәрләренә җәлеп итү максатыннан 2019 елда Татарстанда ТР мөфтие тарафыннан 9 студент ел саен түләнелә торган стипендия алу бәхетенә иреште. Татарстанның һөнәри мөселман уку йортлары (мәдрәсәләре) арасында ислам дисциплинасы һәм гарәп теленнән олимпиада үткәрелде. Аның төп бүләге – Хаҗга юллама иде.

**■ Айгөл Биктимирова,**
**Социаль үсеш бүлеге җитәкчесе**

# Татар теленең Рәсәйдә шәрык дипломатиясенең теленә әверелүе



**Петр I нең татар телендәге Манифесты**

Татар теле борынгы һәм өзлексез язма-әдәби гореф-гадәтләре булган төрек телләре исәбенә керә. XVI-XVIII гасырның иске татар әдәби теле үзенең башлангычын, үз чиратында бик борынгы X-XII гасырлардагы карахан-уйгыр әдәби телләренә барып тоташып, XIII-XV гасырдагы Алтын Урда әдәби телләреннән ала.

Алтын Урда чорында әдәби телнең рәсми стиле формалаша. Без аны Урда ханнарының ярлыкларында күрә алабыз. Алтын Урда таркалганнан соң рәсми татар теленең яңа үсеш этабы Казан ханлыгы чорына туры килә. XIV гасыр азагы XV гасыр башында Мәскәү дәүләте үзенә хезмәткә күбрәк татар кешесен җәлеп итә башлый һәм шул рәвешле «хезмәт итүче татарлар» барлыкка килә. Нигездә, болар Мишәр Йорты татарлары була. Мәскәү кенәзләре аларны хезмәткә чакырып, кызыксындыруның төрле формаларын уйлап таба. Барыннан да бигрәк бу алар өчен җир бүлеп бирүдә чагыла.

Әлеге кешеләрнең кайберләре кенәзләрнең тәрҗемәчеләре һәм илчеләре сыйфатында хезмәт итә, чөнки татар теле Алтын Урда, ә алга таба татар ханлыгы белән мөнәсәбәтләрдә аерылгысыз өлеш алып тора. Рус кенәзләре арасында татар телен белү бик дәрәҗәле эш булган.

1552 елда Казан ханлыгын яулап алулардан соң Мәскәү дәүләте рус булмаган халыклар яшәгән өлкәдә дә үзенең хакимиятен тарата. Ул хәрби-административ характердагы чараларның яулап алган җирлекләрдә тотрыклылык саклап калуында шикле булачагын аңлый. Шуңа күрә Иван IV хезмәткә рус хакимиятенә начар мөгамәләдә булмаган татар феодалларын ала. Алар да хезмәт итүче татарларның бер өлешенә әверелә.

Казан ханлыгы таркалганнан соң да Идел буе татарларының рәсми язу теле үзенең әһәмиятен югалтмый. Ул Рәсәй дәүләте кысаларында яңа үсешкә ирешә. Кытайдан алып Балкан ярымутравына кадәр булган киңлекләрдә төрек телләренең киң таралуыннан соң, татар теле бик күп шәрык илләре белән дипломатик язышу һәм аралашу теленә әйләнә.

Бу чорда татар теле шәрыкта Рәсәй дипломатиясенең төп теле дип санала. XIX гасырның уртасына кадәр Һиндстан, Кытай, Иран кебек шәрык илләре белән язышуларда нәкъ менә татар телен кулланганнар. Мәсәлән, шәрык телләрен өйрәнүче танылган рус галиме Бартольд Василий Владимир улы (1869-1930) болай дип яза:

«Татар теле Рәсәй белән Иран арасында дипломатик мөнәсәбәтләрдә хезмәт итте. Шулай ук Екатерина II гә хәтле Мәскәү патшаларының шәрык илләре белән хат язышулары татар телендә барды». [Бартольд В.В. Шәрыкның Аурупода һәм Рәсәйдә өйрәнелүенең тарихы // Сочиненияләр.- М., 1977.- Т.IX.- 199 бит].

Ә Рәсәй дәүләте йогынтысына кергән Бохара әмирлегенә, Коканд, Хивин һәм Казак ханлыгына карата мөнәсәбәтләрдә бу тенденция XIX гасырның азагына кадәр дәвам иткән. Татар телендә империя белән казак идарәсе элитасының мөнәсәбәтләрен чагылдырган рәсми документлар (хәрби ант, мактау грамотасы) гына түгел, ә дәгъвалар, хатлар, рапортлар һәм башка бюрократик документлар эшләнә [Казахстан сәясәтенең төзелеш тарихы. 32-33, 38 битләрне карарга].

Ибраһим ханның (идарә итү еллары: 1467-1479) ярлыгы Казан ханлыгы чорларында иң рәсмиэшлекле стиль үрнәге булып тора. Документ Мәскәүдә Рәсәйнең дәүләт архивының борынгы актларында саклана.

■ **islam-today.ru сайтыннан**

# Болгарлылар ни белән шөгыльләнгәннәр?

Тарих дәреслекләрендә Владимир-Суздаль кенәзе Андрей Боголюбский архитектураны бәяли белүче кеше итеп күрсәтелә. Ул яшәгән заманда төзелгән кайбер сарайлар һәм чиркәүләр безнең көннәргәчә сакланган.

X гасырда болгарлар кирпеч җитештерә башлыйлар, аннан чүлмәк яндыру, чуен кою өчен мичләр һәм ике-өч катлы йортлар салалар. Тел белгечләре фикеренчә, «кирпеч» сүзе безгә болгар теленнән килгән һәм «коры даич» дигән мәгънәгә ия, ягъни «мичтә киптерелгән балчык», дигәнне аңлата.

Болгар шәһәрләрендә һөнәрчелек һәм сәнгатьнең балчыктан чүлмәк ясау, металл кою, ташка чокып бизәк төшерү кебек төрләрен камил белгән архитекторлар һәм төзүчеләр, рәссамнар һәм һөнәрчеләр эшли.

Археология мәгълүматларына караганда, болгар осталары аркылы балта ярдәмендә эшкәртелгән тактаны киң файдаланганнар, пычкыны да белгәннәр. Алар бүрәнәләрне чөй белән һәм терсәкле тоташтыру алымын да файдаланганнар һәм моны бик оста башкарганнар.

X-XIII гасырларда чүлмәк ясау һөнәре гөрләп чәчәк ату чорын кичерә. Керамик әйберләрнең югары сыйфатлы булуы җирле осталарның күп яктан югары яндыру культурасына ирешүләре белән бәйле. Яндыруда төрле фазалар һәм югары температура режимы кулланып, осталар савытлар өстендә төрле төсле буяулардан үзенчәлекле гамма тудыралар: төсләр кызгылт-көрән яки кара диярлек нигездән кызыл урта өлеш аша нәфис күксел-соры «тәҗ»га күчә.

Идел Болгарында бик оста итеп бөгелүчән тимерчыбык сузалар, аннан төрле предметлар эшлиләр. Бу тимер предметлар үзгә сыйфатлы тимердән эшләнә. Болгарлылар беренчеләрдән булып ату коралы җитештерә башлыйлар.

Идел Болгарында борын заманнардан ук икмәк күп була. Иген уңмаган елларда ул Суздаль Русен һәм Новгородны ипи белән тәэмин итеп тора.

Терлекчелек хуҗалыкның әйдәп баручы өлкәсен тәшкил иткән. Болгарлылар нигездә ат, мөгезле эре терлек, кәҗә, шулай ук тавык, каз, үрдәк үрчеткәннәр. Ул вакытта Болгарда дөяләр дә, безнең заман өчен экзотик хайваннар да була. Алар йөк ташый торган хайваннар буларак китереләләр, әмма болгарлар аларга атланып та йөриләр.

Болгардан чит илләргә кыйммәтле мехлар һәм шулардан тегелгән туннар чыгарыла. Шагыйрь һәм тарихчы Әс-Сәгалиби (961—1038) тире иләүче була, туннар тегү һәм сату белән шөгыльләнә. Шунлыктан аның «Болгар кеш һәм төлке тиреләре белән дан тотты», дигән сүзләре бу уңайдан аерым бер кызыксыну уята.

Болгар осталарының традицияләрен казанлылар дәвам итә. XV—XVI гасырларда Казаннан мехлар һәм мех туннар чыгарыла.

Елъязмачының күн итекләр турындагы хәбәре кызыклы. 985 елда Киев кенәзе Владимир күршеләре өстеннән җиңүгә ирешә. Аның гаскәрләре тарафыннан әсирлеккә алынган болгар сугышчыларының күн итектән булуларын күреп, славяннар гаҗәпкә калалар.

Идел Болгарында сәүдә югары үсешкә ирешкән була. Н. М. Карамзин болгарларның сәүдә итәргә аеруча яратуларын ассызыклап әйтә.

Биләрдә табылган күп санлы гәрәбә әйберләр Болгар белән Балтыйк буе арасындагы бәйләнешләрне ачык күрсәтә, аларның күпчелеге мәдәни катламның (XII—XIII гасыр башы) югары өлешендә табылган. Анда шулай ук Византиядә эшләнгән әйберләр, пыяла бизәнү әйберләре һәм савыт-саба, керамика, амфора табылган.

Кыйммәтле мехлар, су юллары һәм коры җир буйлап күп чакрым араларны үтеп, Урта Иделдән Кытай базарларына килә.

Болгарлар монголларга кадәрге чорда ук гаҗәеп төзелеш осталары булганнар, аларның даны ерак чит илләрдә дә билгеле булган. Биредә чүлмәк ясау, металл кою, таш кисү кебек һөнәрчелек һәм сәнгать төрләре үсеш алган, аларның кайберләре безнең көннәргәчә сакланган.

Болгарның үзендә җитештерелгән товарларны күпләп сату шактый зур табыш китергән һәм үз чиратында һөнәрчелек һәм авыл хуҗалыгын үстерергә мөмкинлек биргән. Тулаем алганда, Болгар дәүләте икътисадында сәүдә зур роль уйнаган. Болар барысы да Идел Болгарының икътисади яктан нык үскән дәүләт булуын раслый. Н. М. Карамзин аның гөрләп чәчәк атуын билгеләп үтә. Монголларга кадәрге чорда Идел Болгарының алга киткән ил булуы хакында башка чыганаклар да сөйли.

■ **И. Ә. Гафаров,**
**«Болгар-Казан тарих көзгесендә»**
**китабыннан**

# Тәкъвалыкның иң югары дәрәҗәсе

**Кыйсса**

Ибне Мөбарәк рахимәһуллаһи Сүриядә хәдисләр язганда каләмен сындыра. Шулчакта үзенең бер танышының каләмен алып тора. Хәдисләр язуын тәмамлап, каләмне савытына урнаштырып куеп, хуҗасына кайтарырга оныта. Сүриядә эшләре беткәннән соң, Мәрва шәһәренә кайткач, савыттагы каләмен күреп, хуҗасына тапшырмаганы исенә төшә. Ибне Мөбарәк кичекмәстән Сүриягә юлга кузгала. Килеп җитеп, каләмне хуҗасына биргәч, Мәрвага кайтып китә.

**Нәсыйхәт:**

Хакыйкый тәкъвалык шундый булырга тиеш. Ибне Мөбарәк: «Ул минем танышым һәм миңа бернәрсә дә әйтмәячәк, каләмне очрашкач кайтарырмын әле», – дими, ә самолетлар, поездлар, машиналар булмаган заманда, малын иясенә кайтарып бирер өчен, озын юл үтә.

# Гөнаһ һәм тәүбә

**Кыйсса**

Берьюлы Ибраһим галәйһиссәлам гөнаһ кылучы кешене күреп: «Йә, Аллаһым аны һәлак ит», – дип ләгънәт кыла башлаган. Моннан соң ул бу кешенең әлеге гөнаһны кылуын өч тапкыр күргән һәм һәрберсендә дә «Йә, Аллаһым аны һәлак ит», – дип әйткән.

Аның мондый сүзләренә җавап итеп Аллаһы Тәгалә болай дигән: «Йә, Ибраһим! Әгәр дә мин гөнаһ кылган һәрбер колымны һәлак итә торган булсам, җир йөзендә кешеләр бик аз булыр иде. Минем колларымның берәрсе гөнаһ кылса, мин аңа җәза бирүне кичектерәм, әгәр тәүбә кылса, аның тәүбәсен кабул итәм».

**Нәсыйхәт:**

Ибраһим галәйһиссәламнең ләгънәте берәүнең Аллаһы Тәгаләнең милкендә Аңа карата итагатьсезлек күрсәтүенә түзә алмаганга күрә әйтелгән.

Әгәр дә без кемнеңдер гөнаһ кылуын күрсәк, түбәндәге өч гамәлнең берсен эшләргә тиешбез:

1. Үзебезнең бу гөнаһны кылмавыбызга шөкер итеп, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булырга, чөнки гөнаһ кылучы урынында без дә була ала идек.

2. Кардәшебез өчен Аллаһы Тәгаләдән аны гөнаһлы, начар гамәлләрдән коткаруын сорап дога кылырга. Аллаһы дуслары нәкъ менә шулай эш итә.

3. Аллаһы Тәгаләдән киләчәктә гөнаһка төшүебездән саклавын үтенергә. Әллә берәр кешедә киләчәктә дә тәкъвалы булачагына гарантия бармы?

# Ихлас йөрәктән кылган доганың кабул булуы



**Кыйсса**

Муса галәйһиссәлам Аллаһыга ихтыяҗын канәгатьләндерүне сорап дога кылучы берәүне күреп, үз-үзенә: «Әгәр дә аның догасын кабул итү минем ихтыярымда булса, мин моны эшләр идем», – дип әйтә.

Бу сүзләренә җавап итеп, Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә вәхи иңдерә: «Мин аңа сиңа караганда да мәрхәмәтлерәк. Әйе, ул Миңа дога белән ялвара, әмма моны теле белән генә эшли. Бу кешенең сарык көтүе бар һәм ул йөрәге белән алар янында, көтүе турында уйлый. Ә Мин йөрәге Минем белән булмыйча, башка берәү янында булган кешенең догасын кабул итмим», – дип әйтә.

Муса галәйһиссәлам тиз арада әлеге кешегә Аллаһы Тәгаләдән үзенә килгән вәхи турында хәбәр итә. Бу кеше шундук йөрәген Аллаһыга юнәлтә һәм Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул кыла.

**Нәсыйхәт:**

Кеше кулларын күтәреп Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать иткән кебек, йөрәге белән дә Аллаһыга юнәлгән булырга тиеш.

Раббыбыз Коръәндә болай дип әйтә:

**«Раббыгызга тыйнаклык белән яшерен дога кылыгыз».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:55

«(Расүлем!) Әйт: «Догагыз (һәм гыйбадәтегез) булмаса, Раббым сезгә нинди әһәмият бирсен?»

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләре тапшырыла:

«Аллаһы Тәгалә каршында догадан да кыйммәтле бер нәрсә дә юк» (Имам Тирмизи һәм Имам ибне Мәҗенең хәдисләр җыентыгыннан).

«Дога – гыйбадәтнең асылы» (Имам Тирмизи һәм Имам Табәранинең хәдисләр җыентыгыннан).

Дога кабул булсын өчен берничә шартны үтәргә кирәк. Доганың ун әдәбе бар:

Доганы кабул булуы яхшырак булган вакытларда кылырга тырышу;

Хасил булган рухи халәтне бүләк итеп кабул итү;

Доганы кыйбла тарафына юнәлеп, кулларны күтәреп кылу;

Доганы тавышсыз кылу;

Дога кылган вакытта ясалма сүзләрдән качу, йөрәктән килгән сүзләрне генә әйтү;

Доганы ихластан һәм курку белән һәм Аллаһының доганы кабул итүенә өметләнү белән кылу;


Доганың кабул булуына ныклап ышану;

Үзеңнең догаларыңда ныклык күрсәтү, аларны өч мәртәбә кабатлау;

Доганы Аллаһыны мактау сүзләре белән башлау;

Дога кабул булуның нигезе – яшерен әдәпләр, мәсәлән, ризыгыңа харам кушмау.

# Акыллы кеше



**Кыйсса**

Берьюлы арыслан, бүре һәм төлке ауга чыгалар һәм кыргый ишәк, газель һәм куян тоталар. Арыслан бүрегә:

– Моны безнең арада бүл, – дип әйтә.

Бүре:

– Кыргый ишәк – арысланга, газель миңа, ә куян төлкегә, – ди.

Моны ишетеп арыслан бүрене ботарлап ата. Аннары төлкегә мөрәҗәгать итеп:

– Бу табышны безнең арада син бүл, – ди.

Төлке:

– Ишәк арысланның төшке ашы, газель кичке ашы булыр, ә куян җиңелчә ашамлык урынына кулланылыр, – дип хәл итә.

Арыслан:

– Болай бүлергә каян өйрәндең? – дип сорый.

Төлке:

– Моңа мине бүре белән булган хәлләр өйрәтте, – дип җавап бирә.

Шуның өчен: «Акыллы кеше чит кешеләрнең хаталарында өйрәнә», – дип әйтелгән.

**Нәсыйхәт:**

Бу очракта бүре мисалында безгә хәтле яшәгән халыкларны санарга була. Коръәни Кәримнең күп кенә аятьләрендә мисал итеп алар турындагы кыйссаларны бәян ителә:

**«Алар (мөшрикләр), җирдә йөреп, үзләреннән алда яшәгән (инкярчы) кешеләрнең (фаҗигале) ахыры нинди булганын күрмәделәрме?»**

«Йосыф», 12:109

**«Алардан алдагы гасырлардан ничәмәләрен һәлак итүебез аларга һидаять бирмәдеме, (бүген бит алар) аларның (вәйран булган) йортлары өстендә йөриләр».**

«Сәҗдә», 32:26

Аллаһы Тәгалә Коръәндә элеккеге халыклар кылган җинаятьләр һәм моның өчен аларга килгән бәлаләр турында хәбәр итә. Шул рәвешле Аллаһы Тәгалә безгә: «Йә Мөхәммәд пәйгамбәр өммәте! Бу элеккеге халыклар кылган җинаятьләр һәм аларга килгән бәлаләр. Әгәр аларны кылсагыз, сез дә шул хәлгә төшәчәксез», – ди.

Шулай ук Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләр һәм тәкъва кешеләр кылган яхшы гамәлләр турында да сөйли. Бу рәвешле ул: «Әгәр сез дә мондый күркәм эшләр кылсагыз, Мин сезне шулар яки аннан да яхшырак нигъмәтләр белән бүләкләрмен», – дип әйтә.

Төлке бүре белән булганнардан сабак алган кебек, без дә элеккеге заманнарда яшәгән халыкларның тормышларыннан гыйбрәт алырга тиешбез.

■ **«Рухуль-Бәйан» китабыннан тәрҗемә**

# Кайгыда булганнарга

Кеше яралганнан алып үлеменә кадәр авырлыкларда. Аның ана карынында 9 ай булуы, әнисенең тилмереп аны саклап йөрүе булсынмы. Кеше дөньяга барлыкка килгәндә, әнисенең тулгак белән авырдан бала табуымы. Үсә торгач, дөнья авырлыклары барлыкка килә: һәрвакыт акча җитми, гаиләсе булгач, балалары тугач, ул янә авырлыкларда, төшенкелектә яши: балаларның мәктәп проблемалары, аларны урнаштыру һ.б.

Һәм аның бу авырлыклары һич тә туктамый, ул һич тынычлана алмый. Ә бит Ахирәткә, бакый дөньяга күчкәч, анда тагын да зуррак авырлыклар, кайгылар башлана.

Димәк, тормыш авырлыклары – ул Аллаһы тарафыннан килә торган сынаулар. Без ул авырлыкларны ничек итеп каршылыйбыз, нинди сүзләр әйтеп, нинди эшләр эшләрбез икән?

Шуңа күрә ул авырлыкларның, ул сынауларның иң зурларын Аллаһы пәйгамбәрләргә, илчеләргә бирде. Һәм дә ул пәйгамбәрләрнең җаваплары, сынауларны үтүләре безнең өчен яхшы үрнәк булды.

Аллаһының илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иң зур бәла-казалар пәйгамбәрләргә килә. Моннан җиңелрәкләре – изгеләргә. Аннан да җиңелрәкләре – изгеләрнең дәрәҗәләреннән түбәнрәкләргә», – дип әйткән.

Пәйгамбәрләр арасында зур бәлага очраган Әюб пәйгамбәр бар иде. Аның байлыгы, мал-мөлкәте, балалары күп иде. Ләкин көннәрдән бер көнне Аллаһы тәкъдире буенча мал-мөлкәте юкка чыга, балалары бербер артлы үлеп бетә, сәламәтлеге какшый, бик каты авырый башлый. Бер аять тәфсирендә «Әюб галәйһиссәлам лепра чире (барыс авыруы) белән чирли башлый» дип әйтелә.

Мондый халәтендә Әюб галәйһиссәлам Аллаһыга ялварды, Аңа дога кылды, бөтен дөньяны каргап, төшенкелеккә бирелеп утырмады. Аның авырлыкларга каршы торуы – безнең өчен күркәм мисалдыр.

Ә бүген нәрсә? Бүген кешегә чебен очы кадәр генә авырлык килсә дә, ул кайгысында бөтен дөньяны гаепли, язмышына, Аллаһы тәкъдиренә көферлек сүзләре яудыра башлый. Кайгы вакытында Раббысы барлыгын, кайгыларны бетерүче, догаларны кабул итүче барлыгын оныта, хәтта кайгыга бирелеп тормышы аска таба тәгәри. Ә бит бу безнең дөньябыз – фани дөнья. Үзебез дә бу дөньяга мәңгелеккә килмәгәнбез. Әле алда безне мәңгелек Ахирәт тормышы көтә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам тормышында да зур авырлыклар булды. Расүлебез галәйһиссәламне Мәккә мөшрикләре эзәрлекләп, аны үтерергә теләгәндә, Аллаһы аңа Мәккәдән Мәдинәгә күченергә әмер итә. Ул иң якын иптәше Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе белән юлга чыга, ләкин артларыннан мөшрикләр куалый башлый. Шулардан качарга теләп, тау башына менеп, кечкенә генә тау тишегенә керәләр, шунда качып утыралар. Ләкин дошманнары аларга якынайгач, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе: «Әй, Аллаһының Илчесе! Әгәр боларның берәрсе аяк астына караса, безне күрәчәк», – дип әйткәч, Расүлебез: «Әй, Әбү Бәкер! Әгәр бу икәүнең өченчесе – ярдәмче, яклаучы Аллаһы булса, бу икәү турында ни әйтер идең?» – дип аны тынычландыра. Аллаһының Илчесе хәтта мондый авыр вакытта да, үлем куркынычы якын булганда да Аллаһыга бөтен иманы белән юнәлгән, Аллаһыга тәвәккәлләгән, Аннан гына ярдәм көткән.

Шуңа күрә мөэмин-мөселман үзенең тормышына авырлык килсә: «Аллаһы безне ташламас, җиңеллеген бирер», – дип сабыр итәргә тиеш.

Әгәр уйлап карасак, хәзерге көндә без зәгыйфь, мескеннәр, хәтта кечкенә авырлыкларны күреп, төшенкелеккә бireләбез: акча җитмәде, матур күлмәк, пәлтә алып булмады, малай укуын бишлегә тәмамлый алмады, теләгән машинаны алып булмады һәм башка төрле күренешләргә борчылабыз. Бу авырлыкларны да күреп, кешенең дөньясы караңгылана, уй-фикерләре чуала. Безгә кадәр яшәгән пәйгамбәрләр булсынмы, сәхабәләр булсынмы, аларның бәла-казалары безнеке белән чагыштырырлык түгел. Ләкин алар һәрвакыт Аллаһыга ялвардылар. Җиңеллекне сорап дога кылдылар. Аллаһының рәхмәтенә өметләнделәр.

Авырлыкта калдың икән, Аллаһыга ялвар, дога кыл! Бурычларың җыелды икән, Аллаһыга ялвар, дога кыл! Гаиләңә кайгы килде икән, Аллаһыга ялвар, дога кыл! Балаларыңа тәүфыйк-һидаять телисең икән, Аллаһыдан сора, Аңа дога кыл!

Аллаһы Раббыбыз Коръәннең «Иншираx» сүрәсендә болай дип әйтә:

**«Дөреслектә һәр авырлыктан соң җиңеллек килә! Һәр авырлыктан соң җиңеллек килә».**

«Инширах / Ачмак», 94:5-6

Нәрсә генә булмасын, Аллаһы безгә җиңеллекне бирермен диде. Ләкин бездән таләп ителгәне – ул Аллаһыга буйсынып, иманлы рәвештә сабыр булырга һәм дә Аллаһыга тәвәккәлләргә. Хәерлесен бары тик Аллаһыдан гына өмет итәргә кирәк.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әгәр мөселманга нинди дер кайгы килгәндә: «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун. Йә Аллаһы! Бу кайгыга сабыр иткән өчен әҗерләреңне насыйп итсәң иде. Миңа аны яхшылык белән алмаштырсаң иде», – дип әйтсә, Аллаһы ул кайгысына сабыр иткәне өчен әҗер-савапларын насыйп итәр һәм җиңеллек белән кайгысын алмаштырыр», – дип әйтте.

Шунысы да бар: тормышында нинди генә авырлык, кайгы яки хәсрәт килмәсен, бу сиңа әҗер, гөнаһларыңның сөртелүенә бер сәбәп булып тора.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Мөселманга тигән һәртөрле авыру, кайгы-хәсрәт, авырлык, хәтта аягына кергән чәнечке үсемлеге өчен дә Аллаһы аның гөнаһларын ярлыкар, сөртер!» – дип әйткән.

■ **Сәлимҗан хәзрәт Домнин, Кабан арты мәчете имамы**

# Харам, димәк зыянлы

– Әни, карале, бу шоколад хәләлме? – дип йөгереп килгән малайның яулыклы әнисенә төксе караш ташлады янәшәдә торучы олы яшьтәге ханым. Әлбәттә, аның карашында еш кына мөселманнарга әйтелә торган дин катлаулы, сез артык кыланасыз, әллә нәрсәләр уйлап чыгардыгыз, дигән сүзләр ярылып ята иде. Менә шундый мизгелләрнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан бер сынау гына булганын аңлаган яшь мөслимә, ханымның усал карашына җавап итеп, елмаеп карады да, бир, балам, хәзер карыйбыз аны, дип баласын иңеннән кочаклап читкә алып китте.

Мөселман кешесенә мондый һәм аңа охшаш каршылыклар белән еш очрашып торырга туры килә. Ислам диненең күркәмлеген, бөеклеген, пакьлеген аңлаган мөэмин-мөселман кешесе бу очракларда үзен дөрес тоту, хикмәт белән эш итү ягын карый. Әле диннән ерак булган, аның әһәмиятен аңламаган кешеләргә тупаслык күрсәтү – аларның диннән бөтенләй дә йөз боруга китерәчәген белә. Күркәм әхлаклы, белемле, ихлас мөэмин-мөселман шәригать кануннарын аңламыйча, хәтта кайвакыт килешмичә фикер йөртүчеләр белән сабыр һәм ихтирамлы халәттә аралаша, тыюларның, харам гамәлләрнең нигә нәкъ менә әлеге хөкемдә булганнарын да гыйлеме һәм хикмәте белән аңлатып бирә.

Әгәр дә уйлансак, адәм баласының Аллаһы Тәгалә тыйганнар белән килешмәве, харамны харам дип белмәве аның белемсезлегеннән, тәкәбберлегеннән түгелме икән?! Кешенең һәр харамның зыянлы булуын таныргa теләмәве гаҗәпләндерә торган хәл. Аллаһы Тәгалә тыйган барлык харам гамәлләр ул, иң беренче чиратта, кешенең үзе өчен зыян салуын аңлау мөһим. Кибетләрдә ризыктагы составны укып алган мөселман кешесен «бар нәрсәне дә катлауландыра» дип гаеплиләр. Ә бит югыйсә андагы харам дип табылган төрле кушылмалар, төс кертә торган матдәләр, хәмер кушылу – ризыкны сәламәтлек өчен зыянлы итә. Балалар табиблары ата-аналарга сабыйлары өчен кибеттән нәрсә дә булса сайлаганда аеручa да игътибарлы булырга өнди. Әле ныгымаган организм өчен табигый продуктлардан әзерләнмәгән ризыклар аллергия барлыкка килү, эчәклекләр, ашказаны көйсезләнүгә китерергә мөмкин булуын искәртеп торалар. Әмма динне «катлаулы» дип танучылар бу хакыйкатьтән баш тартып, ризык сайлаганда хәләлгә өстенлек бирүчеләрне гаепләргә ашыга.

Бу ризыктагы хәләллек мәсьәләсенә кагылышлы мисал гына иде. Шәригатьтә моңа охшаш дәлилләр тулып ята. Аллаһы Тәгалә тыйган кайсы гына харам гамәлне алсак та, барысы да безнең өчен зыянлы булганлыгын аңларбыз. Хәтта кеше әһәмият бирми торган ялган, гайбәт сөйләү, сүз йөртү кебек гамәлләр дә кеше тормышлары бозылуга сәбәп булып тора. Тел афәтләре аркасында гаиләләрдә, туганнар, дуслар, хезмәттәшләр арасында килеп чыккан аңлашылмаучанлыклар, үпкә, ызгыш-талашларның саны бихисап. Менә шуларны белә торып кеше диндәге тыюларны «катлауландыру» дип атый. Ислам ул – кеше тормышын авырайту түгел, ә киресенчә дөрес яшәү рәвеше. Хак мөэмин мөселман кешесенең бурычы: моны аңлап һәм үтәп яшәү генә түгел, ә моның хикмәтен әйләнә-тирәдәгеләргә дә төшендерә алу.

■ **Айсылу Юлдашева**

# Агулы сабак

***Дәвамы. Башы алдагы санда***



– Аннан котылмыйча, яхшы, тыныч тормыш булмаячак! – диде ул сөйләгәннәрен җөпләп, һәм «мине сатмас микән?» дигән шикелле әбекәйгә сагаеп карап куйды. Ләкин әби рухи яктан изаланып беткән кызны гаҗәпләндереп, аңа теләктәшлек белдергәндәй башын какты да:

– Ярый кызым, аңладым. Котыласы булгач, котыласы инде. Агуларбыз биемеңне. Минем моның өчен кирәкле үләннәрем дә бар... – дип күзләрен серле итеп ялтыратып алды. Астагы тартмаларында бераз актарынганнан соң, ул Раилә алдына берничә кечкенә төргәген чыгарып салды да, кызны якын иткәндәй пыш-пыш килеп, болай диде:

– Син, кызым, шунысын аңла: биемеңне кинәт кенә, бер минут эчендә агуласаң, шундук синнән шикләнәчәкләр. Шуңа күрә мин сиңа кешене акрынлап бетерә торган үләннәр төнәтмәсен ясарга өйрәтәм. Шуның бер кашыгын каенанаң ризыгына сиздермичә генә өстәп болгатырсың – берничә айдан дошманың үлем түшәгенә ятачак. Әмма сак бул: кеше-кара белә күрмәсен...

Карчыкны зур игътибар белән тыңлап, күңел аша үткәрелгән һәр сүзенә диярлек «әйе, ярар» дигән сыман башын кагып торган Раилә шулай җайлы гына ярдәмче-фикердәше табылуына сөенеп бетә алмады. «Фикердәше» исә янә як-якка каранып алып, пышылдавын дәвам итте:

– Һәм тагын бер бик мөһим киңәш: бүгеннән башлап аңа якты чырай күрсәтеп, гел елмаеп тор: янәсе синең ниятеңдә бернинди яманхәтәр юк... Нәрсә генә дисә дә, яхшы сүз белән җавап кайтар, аңа карата гел ихтирамлы, илтифатлы бул. Шулай итсәң, каенанаң үлгәннән соң, синнән беркем шикләнмәячәк... Аңладыңмы?

Үлән сатучының әйткәннәрен Раилә, әлбәттә, бик яхшы аңлады. Шуңа күрә кайтуына биеме: «Ярты көн «гүләйттә» йөрдең, фәлән син дә төгән!» дип ни генә әйтмәсен, бер сүз каршы дәшмәде, эченнән генә: «Моның үлемтек әйберләре алынган микән?» – дип кенә уйлап куйды. Ире төнгә эшкә китеп, каенанасы яткannан соң, Раилә аш бүлмәсендә табаксавыт белән маташкан булып, базарда сатып алынган төргәкләрне чыгарды да, нәкъ үлән сатучы өйрәткәнчә төнәтмә ясады, соңыннан явыз убырдай күзләрен ялтыратып:

– Көннәрең санаулы, озакламый хушлашабыз синең белән, аждаһа... – дип борын астыннан гына мыгырданып куйды.

Иртән бием кәҗәне савып, сөт савытын мич артындагы эскәмиягә куйды да, тавыкларга ашарга салам, дип абзарга чыгып китте. Форсаттан файдаланып, Раилә тиз генә каенанасының зур бизәкле чынаягына сөт салды, аннары төнлә әзерләгән төнәтмәнең бер кашыгын шунда бушатып, болгатып куйды. Каенанасы өйгә керүгә Раилә: «Әни, урын-җиреңне җыештырдым, идәннәрне сөртеп алдым, сиңа сөт салып өстәлгә куйдым, эчәрсең!» – дип сандугачлардай черелдәп, мөлаем елмаеп җибәрде. Каенана нәрсә дияргә дә белмичә, аптырап калды. Шулай да, утырып, бер чокыр сөтне эчеп бетергәч: «Уф, әллә авыз тәме юк шунда...» – дип кенә әйтте дә, бакчага чыгып китте. Менә шул көннән башланды да инде. Раилә биеменә ничек тә ярарга тырышып, якты чырай күрсәтеп, елмаеп кына торды, үзе көн дә иртән агу салынган бер чынаяк сөт әзерләп бирде.

Бервакыт, ишегалдында кер элгәндә, Раилә очраклы гына каенанасының күрше Саимә апа белән урамда, капка алдында сөйләшкәннәрен ишетеп алды.

– Нихәл, Миннисәттәй? Әллә авырыйсыңмы – күренмичә тордың бу арада?

– Үзем исән-сау, Аллага шөкер. Менә киленем генә әллә нишләде бит әле...

– Нәрсә булган Раиләгә?

– Нәрсә булсын? Сәерләнеп китте киленебез: бер сүз каршы әйтми, авызына киртә тотканнармыни...

– Кит аннан...

– Чын менә! Нәрсә кушсаң да, «син дигәндә – аяк идәндә!» дигән шикелле чабып кына йөри. Йөзендә елмаю, телендә – татлы сүз... Хәйран калырсың: бер булмаганны – миңа көн дә хәтта эчәремә сөтне дә әзерләп куя!

Килене белән үзе дә эт белән мәчедәй яшәгән Саимә апа ике кулын селтәп, алъяпкычына кагып алды да: «Вәт заразы!» – дип гаҗәпләнүен белдерде һәм шундук: «Личит итәргә кирәк аны, личит итәргә!» – дип кырт кисеп, хөкем дә чыгарып куйды.

Шулай атналар узды. Һәркөн иртән каенана агу кушылган сөтне эчеп барса да, аны-моны сизенмәде (базардагы әби үләннәрне белеп биргәндер инде, күрәсең). Биеменең озакламый үләсен белгәнгә, Раилә кайвакыт аны кызганып та куя иде. Шуңа күрә мыр-мыр килеп йөрүләренә каршы дәшмәде, киресенчә – назлы тавыш белән «ярар-ярар» дип тәкрарлап, авызын ерып торды. Тора-бара Миннисә апа да килененә мөгамәләсен үзгәртте: үзе дә сизмәстән, каныгуларын киметеп, аңа елмая башлады, кайвакыт онытылып «кызым» дип тә әйткәләде, кыскасы, үзара мөнәсәбәтләре көннән-көн яхшыра барды. Иртән Раилә биеменә сөт әзерләгән булса, көндез һәм кичен каенана (хәтта улы өйдә булмаса да) килененә тәмле итеп чәйләр әзерләп эчертә башлады, аның татлы сүзләренә матур итеп җавап кайтарды. Ә бер көнне Раилә каенанасының күрше Саимә апа белән ишегалдында сөйләшкәннәренә аш бүлмәсенең бераз ачык калган тәрәзәсе аша янә шаһит булганнан соң, аптырап, тирән уйга батты. Йомыркага дип кергән җиреннән, сүз иярә сүз чыгып, Саимә апа күршесеннән килене хакында сорашасы итте.

– Теге тәмсез хәсрәтең ничек соң анда – һаман үз туксаны туксанмы? – дип зәһәрләнеп сорап куйды ул, күршесен чәнчүле карашы белән бораулап. Әмма Миннисә апа аңа теләктәшлек белдереп килененнән зарланасы урынга, күршесен көтелмәгән җавабы белән шаккатырды:

– Нишләп хәсрәт булсын ди ул? Күңеле яхшылыкта, изгелектә булган киленемне үз кызымнан да ким күрмим мин хәзер. Миңа шундый килен биргәнгә Аллаһы Тәгаләгә мең шөкер!

Шушы сүзләрне ишетүгә Раилә кулындагы табаны төшереп җибәрә язды. Тора-бара ул үзе дә каенанасын үз әниседәй күреп, аны бөтен җаны-калебе белән яратканын, бик якын иткәнен аңлады. Тик... Йә Алла! Ул бит аны үз куллары белән инде берничә ай кабергә керергә дип әзерләп йөрде. Гадәткә кергәч, теге үләннәр төнәтмәсен бүген дә сөтенә салган иде. «Их, тинтәк мин, тинтәк!» – дип тиргәде үз-үзен Раилә. – Белә торып кешене агулап ят инде, йә! Базардагы әби әйткән вакыт та килеп җитә... Нишләргә?!»

Сәгать инде төнге уникедән авышып китүгә карамастан, Раилә шомлы уйлар тәэсирендә йоклый алмыйча ятты. Җәйге төннең тынлыгын бүлеп черелдәгән чикерткәләр бертуктаусыз: «Тинтә-әк! Тинтә-әк!» – дип черелдәп тора сыман. Инде сәгатьтән артык үзенең дуамал, мәгънәсез, ахмак гамәле турында уйланып, Раилә үз-үзенә бер үк сораулы бирә: нишләргә? Ярый әле Рәсим бүген эштә түгел. Ләкин бит ул хатынының күңел халәтен, гомумән, нәрсә булганын белми, әнә ич – гамьсез мышнап, тыныч кына йоклап ята, җаныкай. Уртаклашып киңәшерлек кеше булмагач, Раилә өй янындагы алмагач ботаклары аша бүлмәне кырыс, хәтта ачулы яктырткан айга мөрәҗәгать итте: ниш-ләр-гә... Ә ул – дәшми. Белмидер инде ул да, нишләргә... Каян белсен? Күңелдә – үкенү. Һәм курку... Әллә Рәсимне уятып бәйнә-бәйнә барысын сөйләргә дә, бу мәсьәләне уртага салып, бергәләп хәл итү юлын эзләп карарга? Юк... Юк-юк, кирәкми... Ул белсә!..

Тагын шулай өзгәләнеп, җан газабыннан җәфаланып бераз яткannан соң, Раилә үз әбисенең «мәхлук белмәс, Аллаһ белер» дигән сүзләрен исенә төшерә. Шуңа да торып авыл мәчете урнашкан якка юнәлеп тезләнә дә, ихластан Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп сорый: «Йә Раббым, нишләргә? Әнкәбезне ничек коткарырга?..» Дога кылып бетерүе була, шундук күңелендә шундый фикер туа: базардагы үлән сатучыга барып, икенче төрле – шифалы, ул биргән агуның зарарын бетерә торган үләннәр сорарга кирәк! Әйе-әйе, нәкъ шулай итәргә кирәк!.

*дәвамы киләсе санда*

■ **Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

### Дүшәмбе

7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Фикх дәресләре
8:15 Бер хәдис - бер җавап
8:35 «Мәслихәт»
9:00 Хикмәтле хикәяләр
9:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
9:30 Әкиятләр иле
09:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
11:00 Гаилә дәресләре
11:30 Балам-багалмам
12:00 Азан
12:05 Сказки снов
12:15 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
12:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
12:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:00 Поучительные истории
13:15 Ислам без стереотипов
13:30 Учимся читать намаз
14:00 Есть хадис - есть ответ
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Фикх дәресләре
17:15 Бер хәдис - бер җавап
17:35 «Мәслихәт»
18:00 Хикмәтле хикәяләр
18:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
18:30 Әкиятләр иле
18:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
20:00 Гаилә дәресләре
20:30 Балам-багалмам
21:00 Сказки снов
21:10 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
21:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
21:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:00 Поучительные истории
22:15 Ислам без стереотипов
22:30 Учимся читать намаз
23:00 Есть хадис - есть ответ
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### Сишәмбе

7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Хәдис дәресләре
8:20 Җан авазы
8:30 «Мәслихәт»
8:50 Әлифба сабаклары
9:00 Хикмәтле хикәяләр
9:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
9:30 1001 хәзинә
9:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
11:30 Бер хәдис - бер җавап
12:00 Азан
12:05 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
12:20 МИМ
12:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
12:45 Сказки снов
13:00 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:10 Поучительные истории
13:30 Ислам без стереотипов
13:45 40 хадисов - 40 толкований
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәдис дәресләре
17:20 Җан авазы
17:30 «Мәслихәт»
17:50 Әлифба сабаклары
18:00 Хикмәтле хикәяләр
18:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
18:30 1001 хәзинә
18:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
20:30 Бер хәдис - бер җавап
21:00 Сказки снов (новый выпуск)
21:10 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
21:30 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
21:45 МИМ
22:00 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:10 Поучительные истории
22:30 Ислам без стереотипов
22:45 40 хадисов - 40 толкований
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### Чәршәмбе

7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Фикх дәресләре
8:15 Бер хәдис - бер җавап
8:35 «Мәслихәт»
9:00 Хикмәтле хикәяләр
9:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
9:30 Әкиятләр иле
09:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
11:00 Гаилә дәресләре
11:30 Балам-багалмам
12:00 Азан
12:05 Сказки снов
12:15 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
12:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
12:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:00 Поучительные истории
13:15 Ислам без стереотипов
13:30 Учимся читать намаз
14:00 Есть хадис - есть ответ
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Фикх дәресләре
17:15 Бер хәдис - бер җавап
17:35 «Мәслихәт»
18:00 Хикмәтле хикәяләр
18:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
18:30 Әкиятләр иле
18:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
20:00 Гаилә дәресләре
20:30 Балам-багалмам
21:00 Сказки снов
21:10 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
21:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
21:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:00 Поучительные истории
22:15 Ислам без стереотипов
22:30 Учимся читать намаз
23:00 Есть хадис - есть ответ
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### Пәнҗешәмбе

7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Хәдис дәресләре
8:20 Җан авазы
8:30 «Мәслихәт»
8:50 Әлифба сабаклары
9:00 Хикмәтле хикәяләр
9:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
9:30 1001 хәзинә
9:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
10:00 Бер мәчет тарихы
10:10 Бәрәкәтле гаилә
11:00 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
11:30 Бер хәдис - бер җавап
12:00 Азан
12:05 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
12:20 МИМ
12:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
12:45 Сказки снов
13:00 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:10 Поучительные истории
13:30 Ислам без стереотипов
13:45 40 хадисов - 40 толкований
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Хәдис дәресләре
17:20 Җан авазы
17:30 «Мәслихәт»
17:50 Әлифба сабаклары
18:00 Хикмәтле хикәяләр
18:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
18:30 1001 хәзинә
18:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
19:00 Бер мәчет тарихы
19:10 Бәрәкәтле гаилә
20:00 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
20:30 Бер хәдис - бер җавап
21:00 Сказки снов (новый выпуск)
21:10 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
21:30 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
21:45 МИМ
22:00 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:10 Поучительные истории
22:30 Ислам без стереотипов
22:45 40 хадисов - 40 толкований
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### Җомга

7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Фикх дәресләре
8:15 Бер хәдис - бер җавап
8:35 «Мәслихәт»
9:00 Хикмәтле хикәяләр
9:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
9:30 Әкиятләр иле
09:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
10:00 Намазга өйрәник
10:30 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
11:00 Гаилә дәресләре
11:30 Минбар (Җомга вәгазьләре)
12:00 Азан
12:05 Сказки снов
12:15 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
12:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
12:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:00 Поучительные истории
13:15 Ислам без стереотипов
13:30 Учимся читать намаз
14:00 Есть хадис - есть ответ
14:20 Художественный фильм
16:00 Хәерле сәгатьтә
17:00 Фикх дәресләре
17:15 Бер хәдис - бер җавап
17:35 «Мәслихәт»
18:00 Хикмәтле хикәяләр
18:15 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
18:30 Әкиятләр иле
18:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
19:00 Намазга өйрәник
19:30 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
20:00 Гаилә дәресләре
20:30 Минбар (Җомга вәгазьләре)
21:00 Сказки снов
21:10 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
21:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
21:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:00 Поучительные истории
22:15 Ислам без стереотипов
22:30 Учимся читать намаз
23:00 Есть хадис - есть ответ
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### Шимбә

7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Тәмле булсын
8:20 Җан авазы
8:30 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
8:45 Әкиятләр иле
9:00 Мультфильм (Җилкәй яңа)
9:20 «Рисалә» Каюм Насыйри
9:30 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
10:00 Пәйгамбәр сүзе эзеннән. Художественный сериал
10:40 Хикмәтле хикәяләр
11:00 Гаилә дәресләре
11:30 «Мәслихәт»
12:00 Азан
12:05 Сказки снов
12:15 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
12:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
12:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:00 По следам пророческого откровения. Художественный сериал
13:40 Поучительные истории
13:55 Ислам без стереотипов
14:10 МИМ
14:20 Художественный фильм
16:00 Минбар (Җомга вәгазьләре)
16:30 Фикх дәресләре
17:45 Бәрәкәтле гаилә
17:30 Балам-багалмам
18:00 Хәдис дәресләре
18:20 Бер мәчет тарихы
18:30 Тәмле булсын
18:50 Җан авазы
19:00 Пәйгамбәр сүзе эзеннән. Художественный сериал
19:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
20:00 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
20:15 Әкиятләр иле
20:30 «Мәслихәт»
21:00 Сказки снов
21:10 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
21:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
21:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:00 По следам пророческого откровения. Художественный сериал
22:40 Поучительные истории
22:55 Ислам без стереотипов
23:10 МИМ
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

### Якшәмбе

7:00 Хәерле сәгатьтә
8:00 Тәмле булсын
8:20 Җан авазы
8:30 Хәләл
8:45 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
9:00 Әкиятләр иле
9:10 Мультфильм (Җилкәй яңа)
9:30 Тәфсир. Тимергали хәзрәт Юлдашев белән
10:00 Пәйгамбәр сүзе эзеннән. Художественный сериал
10:40 Хикмәтле хикәяләр
11:00 Гаилә дәресләре
11:30 «Мәслихәт»
12:00 Азан
12:05 Сказки снов
12:15 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
12:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
12:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
13:00 По следам пророческого откровения. Художественный сериал
13:40 Поучительные истории
13:55 Ислам без стереотипов
14:10 МИМ
14:20 Художественный фильм
16:00 Минбар (Җомга вәгазьләре)
16:30 Фикх дәресләре
17:45 Бәрәкәтле гаилә
17:30 Балам-багалмам
18:00 Хәдис дәресләре
18:20 Бер мәчет тарихы
18:30 Тәмле булсын
18:50 Җан авазы
19:00 Пәйгамбәр сүзе эзеннән. Художественный сериал
19:40 Мультфильм (Җилкәй яңа)
20:00 Татар телендә мультфильм (Шөкер хуҗа)
20:15 Әкиятләр иле
20:30 «Мәслихәт»
21:00 Сказки снов
21:10 Мультфильм на русском языке (Шекер Ходжа)
21:30 Мультфильм на русском языке (Ветерок)
21:45 Хузур вояж с Антоном Кротовым
22:00 По следам пророческого откровения. Художественный сериал
22:40 Поучительные истории
22:55 Ислам без стереотипов
23:10 МИМ
23:20 Художественный фильм
01:05 Чтение Священного Корана

**Хөрмәтле радиотыңлаучылар!**

"Азан" радиосы сайтының адресы үзгәрде. Хәзер безне azan.fm сылтамасы буенча таба аласыз. Иске мобиль кушымталар да үз эшен туктатты, аларны яңарту кирәк. Моның өчен айфоннарда App Store, андроидларда Play Market'ка кереп, "Азан радиосы" дип җыеп, "обновить" төймәсенә басарга. (Әгәр моңарчы телефоныгызда безнең кушымта булмаган булса, бер дә шикләнмичә куегыз). Әзер! Хәзер сез кая гына барсагыз да, бернинди түләүсез рәхәтләнеп татарча дини радио тыңлый аласыз.

**QR – кодлар:**

Android өчен:

iPhone өчен:

**Сайт:** azan.fm
**Инстаграм:** azan.fm
**Вконтакте:** azanfm
**Телеграм-канал:** azanfm
**Почта:** radio@azan.fm
**Тел.:** 8 (843) 598-09-43




«Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2020 елның беренче яртыеллыгына язылу башланды

- Ярты елга язылу бәясе: 156 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru
сайтының «Подписка» бүлегендә.

Белешмәләр өчен телефон:
+7 (843) 598 09 42

**КАЗАН ӨЧЕН ФЕВРАЛЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ**

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.02.2020 | 05:29 | 06:08 | 07:38 | 12:00 | 14:24 | 16:16 | 18:03 |
| 02.02.2020 | 05:28 | 06:06 | 07:36 | 12:00 | 14:26 | 16:18 | 18:05 |
| 03.02.2020 | 05:26 | 06:04 | 07:34 | 12:00 | 14:28 | 16:20 | 18:07 |
| 04.02.2020 | 05:25 | 06:02 | 07:32 | 12:00 | 14:30 | 16:22 | 18:08 |
| 05.02.2020 | 05:23 | 06:00 | 07:30 | 12:00 | 14:32 | 16:24 | 18:10 |
| 06.02.2020 | 05:21 | 05:58 | 07:28 | 12:00 | 14:34 | 16:26 | 18:12 |
| 07.02.2020 | 05:20 | 05:56 | 07:26 | 12:00 | 14:36 | 16:29 | 18:14 |
| 08.02.2020 | 05:18 | 05:54 | 07:24 | 12:00 | 14:38 | 16:31 | 18:16 |
| 09.02.2020 | 05:16 | 05:52 | 07:22 | 12:00 | 14:40 | 16:33 | 18:18 |
| 10.02.2020 | 05:14 | 05:50 | 07:20 | 12:00 | 14:42 | 16:35 | 18:20 |
| 11.02.2020 | 05:13 | 05:48 | 07:18 | 12:00 | 14:44 | 16:37 | 18:22 |
| 12.02.2020 | 05:11 | 05:46 | 07:16 | 12:00 | 14:46 | 16:40 | 18:24 |
| 13.02.2020 | 05:09 | 05:44 | 07:14 | 12:00 | 14:48 | 16:42 | 18:25 |
| 14.02.2020 | 05:07 | 05:41 | 07:11 | 12:00 | 14:50 | 16:44 | 18:27 |
| 15.02.2020 | 05:05 | 05:39 | 07:09 | 12:00 | 14:52 | 16:46 | 18:29 |
| 16.02.2020 | 05:03 | 05:37 | 07:07 | 12:00 | 14:54 | 16:48 | 18:31 |
| 17.02.2020 | 05:01 | 05:35 | 07:05 | 12:00 | 14:56 | 16:50 | 18:33 |
| 18.02.2020 | 04:58 | 05:32 | 07:02 | 12:00 | 14:58 | 16:53 | 18:35 |
| 19.02.2020 | 04:56 | 05:30 | 07:00 | 12:00 | 15:00 | 16:55 | 18:37 |
| 20.02.2020 | 04:54 | 05:28 | 06:58 | 12:00 | 15:02 | 16:57 | 18:39 |
| 21.02.2020 | 04:52 | 05:25 | 06:55 | 12:00 | 15:04 | 16:59 | 18:41 |
| 22.02.2020 | 04:50 | 05:23 | 06:53 | 12:00 | 15:06 | 17:01 | 18:43 |
| 23.02.2020 | 04:47 | 05:20 | 06:50 | 12:00 | 15:08 | 17:03 | 18:45 |
| 24.02.2020 | 04:45 | 05:18 | 06:48 | 12:00 | 15:10 | 17:06 | 18:47 |
| 25.02.2020 | 04:43 | 05:16 | 06:46 | 12:00 | 15:11 | 17:08 | 18:49 |
| 26.02.2020 | 04:40 | 05:13 | 06:43 | 12:00 | 15:13 | 17:10 | 18:51 |
| 27.02.2020 | 04:38 | 05:11 | 06:41 | 12:00 | 15:15 | 17:12 | 18:53 |
| 28.02.2020 | 04:36 | 05:08 | 06:38 | 12:00 | 15:17 | 17:14 | 18:55 |
| 29.02.2020 | 04:33 | 05:06 | 06:36 | 12:00 | 15:19 | 17:16 | 18:57 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Гыйнвар саны, №1 (294)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъват бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2745
Газетага ярты елга язылу бәясе – 156 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 28 нче гыйнварда таратыла.
График буенча бу санга 27 нче гыйнвар көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.